2012 елның «09» октябрендәге
ПУ-861 номерлы Указына
1 нче кушымта

## 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70 еллыгын Татарстан Республикасында бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча оештыру комитеты турында нигезләмә

1. 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70 еллыгын Татарстан Республикасында бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча оештыру комитеты (алга таба – Оештыру комитеты) 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70 еллыгына багышланган бәйрәм чараларын әзерләү һәм уздыру, шулай ук югарыда күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыруда катнашучы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары), җәмәгать берләшмәләренең, предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмаларының эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү максатларында төзелә.

2. Оештыру комитеты үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына, Россия Федерациясе Президенты һәм Татарстан Республикасы Президенты указларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм боерыкларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Оештыру комитеты турындагы Нигезләмә һәм аның составы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

4. Оештыру комитетының төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча чаралар планына (алга таба – Чаралар планы) тәкъдимнәр эшләү;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләренең, предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмаларының Чаралар планын үтәүгә бәйле бурычларын хәл итү буенча эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү;

Чаралар планын үтәү мәсьәләләрен карау һәм аны корректировкалау буенча тәкъдимнәр эшләү.

5. Оештыру комитеты үз алдында торган бурычларны гамәлгә ашыру максатларында түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләреннән, предприятие, учреждение һәм оешмалардан Оештыру комитеты компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча мәгълүмати материаллар соратып алырга;

Оештыру комитеты компетенциясенә кергән мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән тәртиптә вакытлыча эш төркемнәре төзергә;

үз утырышларына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләре, предприятие, учреждение һәм оешмалар җитәкчеләрен чакырырга.

6. Оештыру комитеты составына Оештыру комитеты рәисе, Оештыру комитеты рәисе урынбасары һәм Оештыру комитетының аның эшендә җәмәгать башлангычларында катнашучы әгъзалары керә.

Оештыру комитеты рәисе булып Татарстан Республикасы Президенты тора.

7. Оештыру комитеты утырышлары кирәк булуга карап уздырыла.

Оештыру комитеты утырышларын Оештыру комитеты рәисе яисә аның кушуы буенча Оештыру комитеты рәисе урынбасары алып бара.

8. Утырышларның көн тәртибен, аларны уздыру урынын һәм тәртибен Оештыру комитеты рәисе билгели.

9. Оештыру комитеты утырышы, әгәр анда Оештыру комитеты әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, тулы хокуклы дип санала.

Оештыру комитеты утырышында мәсьәләләрне карау нәтиҗәләре буенча карарлар кабул ителә, алар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Оештыру комитеты карарлары аның утырышында катнашучы Оештыру комитеты әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, Оештыру комитеты рәисе тавышы хәлиткеч була. Оештыру комитеты әгъзасы утырышта катнашмаган очракта, карала торган мәсьәләләр буенча үз фикерен ул язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, аның фикере Оештыру комитеты утырышы беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә теркәлергә тиеш.

Оештыру комитеты утырышы беркетмәсенә рәислек итүче кул куя.

10. Оештыру комитеты тарафыннан кабул ителгән карарлар алар белән кызыксынган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләренә, предприятие, учреждение һәм оешмаларга җиткерелә.

Оештыру комитеты карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары проектлары әзерләнергә мөмкин.

11. Оештыру комитеты эшчәнлеген матди-техник яктан, документлар белән һәм мәгълүмати тәэмин итүне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты тормышка ашыра.

Татарстан Республикасы
Президентының
2012 елның «09» октябрендәге
ПУ-861 номерлы Указына
2 нче кушымта

## 1941-1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70 еллыгын Татарстан Республикасында бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча оештыру комитеты составы

| | |
|---|---|
| Миңнеханов Рөстәм Нургали улы | Татарстан Республикасы Президенты, Оештыру комитеты рәисе |
| Моратов Равил Фатыйх улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, Оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Анастасий (Меткин Александр Михайлович) | Казан һәм Татарстан митрополиты (килешү буенча) |
| Бәдриев Илдар Фоат улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгы |
| Богачёв Евгений Борисович | Татарстан Республикасы Милли банкы рәисе (килешү буенча) |
| Борһанов Рафис Тимерхан улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министры |
| Власов Валерий Александрович | Татарстан Республикасы Иминлек советы секретаре |
| Водопьянова Татьяна Павловна | Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе рәисе (килешү буенча) |
| Волкова Фәридә Рәхим кызы | Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы |
| Гайзатуллин Радик Рәүф улы | Татарстан Республикасы финанс министры |
| Гайзатуллин Рамил Ринат улы | Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге идарәчесе (килешү буенча) |
| Гафаров Шамил Хәмит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе |
| Горелик Ицхак | Татарстан Республикасы баш раввины (килешү буенча) |
| Гусев Александр Петрович | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Захарова<br>Светлана Михайловна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Имамов Марсель<br>Мөкатдис улы | Россияи Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге идарәчесе (килешү буенча) |
| Иштирәков Хәбир<br>Газиз улы | Татарстан Республикасы Ветераннар (пенсионерлар) җәмәгать оешмалары республика советы рәисе (килешү буенча) |
| Камалтынов Юрий<br>Зимелевич | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе |
| Карузин<br>Владимир Геннадьевич | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсе башлыгы |
| Когогин<br>Сергей Анатольевич | «КАМАЗ» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Коноплёв<br>Александр Юрьевич | Татарстан Республикасы «Ватан берләшмәсе» төбәк җәмәгать яшьләр оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Ларионова<br>Татьяна Петровна | Татарстан Республикасы Президентының социаль мәсьәләләр буенча ярдәмчесе |
| Лоханов<br>Павел Николаевич | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Башкарма хакимият органнары хезмәттәшлеген координацияләү идарәсе башлыгы |
| Метшин Илсур<br>Рәис улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Мironченко<br>Валерий Николаевич | Казан гарнизоны башлыгы, генерал-майор (килешү буенча) |
| Мостюков<br>Ильдус<br>Шайхелислам улы | Татарстан Республикасының Советлар Союзы Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Геройлары, Сугышчан һәм Хезмәт Даны орденнарының тулы кавалерлары иҗтимагый хәйрия оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Погодин<br>Сергей Николаевич | Татарстан Республикасы хәрби комиссары (килешү буенча) |
| Сафин Ленар<br>Ринат улы | Татарстан Республикасының транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Тәхаутдинов<br>Шәфәгать Фәхраз улы | В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Терентьев<br>Александр Михайлович | Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре идарәсе башлыгы |

| | |
|---|---|
| Фәезов Илдус хәзрәт (Фәезов Илдус Әхмәт улы) | Татарстан Республикасы Диния нәзарәте рәисе, мөфти (килешү буенча) |
| Фәйзуллин Ирек Әнвәр улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры |
| Фәррахов Айрат Зәки улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Фәттахов Энгель Нәвап улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Хәбибуллин Рафис Җәүдәт улы | Россия Федерациясе граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казалары нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе башлыгы – Татарстан Республикасы граждан оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры |
| Хәйруллин Илгиз Кәлимулла улы | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Хохорин Артем Валерьевич | Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министры (килешү буенча) |
| Черепанов Михаил Валерьевич | Татарстан Республикасы Милли музееның «Казан Кремлендә Бөек Ватан сугышы музей-мемориалы» филиалы мөдире (килешү буенча) |
| Шәехразиев Васил Габтелгаяз улы | «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Шәйхетдинов Роман Александрович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры |
| Шакиров Минсәгыйть Закир улы | Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы рәисе (килешү буенча) |
| Шәфигуллин Айрат Радин улы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры |
| Шиһабетдинов Альберт Кашаф улы | «ТАИФ» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Юлашев Әхәт Гайнулла улы | Татарстан Республикасы сугыш һәм хәрби хезмәт ветераннары (инвалидлары) җәмәгать оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Якупов Линар Габделнур улы | Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе. |

## 1598. «Перспектива» Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм тормышка ашыру концепциясе турында

Балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм тормышка ашыру буенча бердәм республика системасын булдыру максатларында **карар бирәм**:

1. «Перспектива» Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм тормышка ашыру концепциясен (алга таба – Концепция) (1 нче кушымта) расларга.

2. Концепцияне тормышка ашыру буенча Ведомствоара координация советы төзергә.

3. Концепцияне тормышка ашыру буенча Ведомствоара координация советы турындагы нигезләмәне (2 нче кушымта) һәм аның составын (3 нче кушымта) расларга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Концепцияне тормышка ашыруны тәэмин итүче чаралар күрергә.

5. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына яшьләр сәясәте мәсьәләләрен хәл иткәндә, республика озак вакытка исәпләнгән максатчан һәм ведомство программаларын әзерләгәндә һәм гамәлгә ашырганда Концепциягә таянырга.

6. Федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, предприятиеләргә, учреждениеләргә, оешмаларга һәм җәмәгать берләшмәләренә яшьләр сәясәте мәсьәләләрен хәл иткәндә үз эшчәнлегендә Концепция нигезләмәләрен исәпкә алуны тәкъдим итәргә.

7. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 09 октябрь
№ ПУ-862

Татарстан Республикасы Президентының
2012 елның «09» октябрендәге
ПУ-862 номерлы Указына
1 нче кушымта

# «Перспектива» Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм тормышка ашыру концепциясе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

«Перспектива» Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм тормышка ашыру концепциясе (алга таба – Концепция) Россия Федерациясе Президенты тарафыннан 2012 елның 3 апрелендә расланган Яшь талантларны ачыклау һәм үстерүнең гомуммилләт системасы концепциясен гамәлгә ашыру максатларында эшләнде.

Концепция әйдәп баручылары түбәндәгеләр булган факторлар җыелмасын исәпкә ала.

Россия Федерациясендә һәм Татарстан Республикасында курс алынган технологик яңалыкларны мотивацияләүгә һәм аларны һәркайда кертүгә нигезләнгән инновацияләр икътисады кеше капиталына карата сыйфат ягыннан яңа таләпләр куя, хезмәт базарында структур үзгәрешләр таләп итә.

Өйрәнү сәләте югары булган һәм дисциплинаара өлкәләрдә яңа белемнәр үзләштерә алган, тәвәккәллекне бәяли һәм билгесезлек шартларында карарлар кабул итә ала торган профессионалларга ихтыяҗ формалаша. Четерекле бурычларны хәл итүгә комплекслы якын килергә сәләтле командаларга ихтыяҗ арта. Җәмгыять алдында килеп чыга торган бурычларны күрә, куя һәм хәл итә белүче иҗади шәхесләр аеруча кирәк.

Кеше капиталын формалаштыруның төп факторларыннан берсе буларак, кешенең интеллектуаль-иҗади сәләтләрен мөмкин кадәр нәтиҗәле үстерү һәм файдалану конкурентлык сәләтен арттыруга юнәлдерелгән дәүләт сәясәтенең иң әһәмиятле элементы була бара.

Мондый мөнәсәбәтләр тиз үсә торган барлык илләргә хас. Аерым алганда, бу мәсьәлә буенча Европа Советы тәкъдимнәрендә (Европа Советының сәләтле балаларга белем бирү турындагы 1248 номерлы тәкъдимнәре 1994 елның 7 октябрендә Европа Советының Парламент ассамблеясе тарафыннан хупланды) бер генә илнең дә үз талантларына саксыз ка-

рауга юл куя алмавы билгеләп үтелә, ә интеллектуаль һәм башка потенциалны үз вакытында күрми калуны кеше ресурсларына карата саксызлык күрсәтү димичә булмый.

Яшь талантларны ачыклау һәм үстерү буенча гомуммилләт системасын булдыру Россия Федерациясе Президенты Д.А. Медведевның 2010 елның 30 ноябрендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә Юлламасында беренче дәрәҗәдәге бурыч булып тора. Төбәк программаларына яшь талантларны ачыклау һәм үстерү буенча гомуммилләт системасы концепциясен тормышка ашыруга юнәлдерелгән чараларны кертү турында йөкләмә Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 27 февралендәге Пр-568 ГС номерлы йөкләмәләр исемлегендә дә бар. Сәләтле яшьләргә ярдәм күрсәтү, белем бирү траекторияләрен һәм карьера үсешен тормышка ашыру зарурлыгы Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнехановның 2010 елның 13 октябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасында бәян ителгән.

Белгечләр фикеренчә, сәләтлелек төшенчәсен тормыш дәвамында шәхеснең системалы, үзгәрүчән сыйфаты дип аңларга кирәк, ул эшчәнлекнең бер яки берничә төрендә башка кешеләр белән чагыштырганда тагын да зуррак нәтиҗәләргә ирешү мөмкинлеген билгели. Сәләтлелекне үстерү – кагыйдә буларак, күп факторлар: нәселдәнлекнең, төрле эшчәнлек нәтиҗәсендә үзләштерелә торган социаль мохитнең катлаулы үзара йогынтысы нәтиҗәсе, шулай ук шәхеснең индивидуаль сәләтне формалаштыру һәм тормышка ашыру нигезендә ята торган үзлегеннән үсешенең психологик механизмнары.

Хәзерге заман фәне яшьләрнең күп кенә вәкилләрендә эшчәнлекнең төрле төрләрендә казанышларга ирешү өчен потенциаль алшартлар булуны билгеләп үтә, әмма аларның бик азы гына чынлап та зур нәтиҗәләргә ирешә. Сәләтле шәхеснең уңышлы үсеше белем бирү системасы мөмкинлекләренә генә түгел, эшчәнлекнең мотивациясен формалаштыруга ярдәм итә торган шартларга һәм сәләтле шәхеснең формалашу нигезен тәшкил итүче кыйммәтләр системасына да бәйле.

Балалар һәм яшьләр сәләтенең формалашкан типологиясе бик схематик рәвештә һәм аның төрле формаларының һәм төрләренең катлаулылыгын һәм күпьяклылыгын чагылдырмый. Стратегик каршылыклардан чыгып, сәләтлелекнең аерым төрләрен үстерү һәм тормышка ашыру түгел, ә балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын киңрәк мәгънәдә үстерү һәм тормышка ашыру бурычы актуальләштерелә.

Концепция сәләтле (талантлы) балаларны һәм яшьләрне ачыклау, аларга ярдәм күрсәтү һәм алар белән кызыксынып тору буенча бердәм ачык республика системасын булдыруга йөз тота. Анда аны тормышка ашыру максатлары һәм бурычлары, төп принциплары һәм механизмнары, юнәлешләре билгеләнә, көтелә торган нәтиҗәләре формалаша. Концепция проблемага гомуми карашны һәм аны хәл итүгә карата эшчәнлекнең бу өлкәсендә эшләнә һәм гамәлгә ашырыла торган чаралар нигезенә салынырга тиешле принципиаль мөнәсәбәтләрне чагылдыра торган стратегик характердагы документтан гыйбарәт.

Концепция «2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү программасын раслау турында» 2011 елның 22 апрелендәге 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү программасын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2010 – 2015 елларга Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү буенча «Киләчәк» – «Будущее» стратегиясен раслау турында» 2010 ел, 30 декабрь, 1174 номерлы карары белән расланган 2010 – 2015 елларга Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү буенча «Киләчәк» – «Будущее» стратегиясен тормышка ашыру бурычларын, шулай ук дөньядагы һәм илебездәге иң яхшы тәҗрибәне исәпкә алып эшләнде.

Концепция Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын нәтиҗәле үстерүне һәм тормышка ашыруны хокукый, оештыру-идарә итү, финанс-икътисадый, фәнни, мәгълүмати, кадрлар белән тәэмин итү системасын төзүне күздә тота. Монда эш бирүчеләрнең, бизнес, фәнни берләшмәләр, дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары, иҗтимагый берләшмәләр, коммерциячел булмаган оешмалар һәм фондлар вәкилләренең бу максатларда социаль партнерлык принципларында берләшүе төп роль уйнарга тиеш. Концепцияне гамәлгә ашыру чараларының әһәмиятле тасвирнамәләре булып үзгәрүчәнлек, бурычларның кирәкле дәрәҗәсенә һәм масштабына җайлашу мөмкинлеге торырга тиеш.

Балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын ачу сәләтлелекнең (һәм аларның берничәсе берләшүнең) күренә торган төрле билгеләрен үстерү һәм тормышка ашыру эшчәнлеген күздә тота, алар арасында интеллектуаль, иҗади һәм сәнгать, спорт, социаль өлкәләрдә күренә торган билгеләр санала. Концепция балаларда һәм яшьләрдә креативлылык-

ны һәм иҗат итү культурасын, эшлеклелекне үстерүгә, фәнни тикшеренү эзләнүенә мөмкин кадәр күбрәк балаларны һәм яшьләрне тарту бурычы белән лидерлыкны стимуллаштыруга, яшәү урынына һәм социаль хәлгә бәйсез рәвештә аларның кирәк булу һәм һәркем ирешә алу мөмкинлеген арттыруга йөз тота. Концепцияне тормышка ашыру ачыклана торган сәләтле балалар һәм яшьләр санын арттыруга, җәмгыять эшчәнлегенең төрле өлкәләрендә аларның үз мөмкинлекләрен тормышка ашыру өчен шартлар тәэмин итүгә булышлык күрсәтәчәк, республиканың интеллектуаль, иҗади, спорт һәм бизнес-элитасын формалаштыруга эзлекле һәм системалы характер бирәчәк, Татарстан Республикасының конкурентлылык өстенлекләре артуга ярдәм итәчәк.

### 1.1. Сәләтле (талантлы) балаларны һәм яшьләрне ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү буенча дөньякүләм һәм илебез тәҗрибәсе

#### Чит илләр дәүләтләрендә сәләтле (талантлы) балаларны һәм яшьләрне ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү

Дөньякүләм тәҗрибәдә сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр белән эшләүгә карата ике төрле мөнәсәбәт күзәтелә:

1. Эксклюзив, ул сәләтле балалар махсус белем бирү программаларына һәм шартларына мохтаҗ булудан килеп чыга.

2. Инклюзив, ул тар төркемнең сәләтен ачыклау өчен түгел, ә барлык балалар һәм яшьләрнең талантын үстерү өчен шартлар тудыруга өстенлек бирә.

Алга киткән илләрнең бүгенге көндәге эш тәҗрибәсендә ике төрле мөнәсәбәттән файдалану тенденциясе күзәтелә. Мондый тәҗрибәнең максаты булып сәләтле (талантлы) балаларны һәм яшьләрне үстерүгә карата, аларның сәләтләрен һәм талантларын ачыклау һәм үстерү өчен шартлар тәэмин итеп, махсус мөнәсәбәт булдыру кирәклеген тану тора.

Шуның белән бергә, сәләтлелекнең бердәм билгеләмәсе юк, тормышта еш кына бу төшенчәне үз эченә ала торган тасвирнамәләр җыелмасы файдаланыла. Мәсәлән, 1990 елда Гонконг мәгариф комиссиясе элек АКШ Конгрессы тарафыннан хупланган сәләтлелек тасвирнамәләрен кабул итте. Бу тасвирнамәләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

гомуми интеллектуаль сәләтләрне;

үзенчәлекле академик күнекмәләрне;

креатив һәм продуктив фикерләүне;

лидерлык сәләтләрен;

сынлы сәнгать һәм башкару сәнгате өлкәсендәге сәләтләрне.

1975 елда халыкара җәмәгать оешмасы – Балалар таланты һәм сәләте буенча Бөтендөнья советын төзү сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр белән эш тәҗрибәсен таратуны активлаштыруга, фәнни тикшеренүләрне координацияләүгә этәргеч бирде.

Күп кенә илләрдә шуннан соң фәнни-тикшеренү, координация, мониторинг эшчәнлеген, шулай ук сәләтлелекнең хөкүмәтләр һәм һөнәри берләшмәләр өчен идарәчел карарлар әзерләүне бергә бәйләп алып бара торган илкүләм үзәкләре төзелде. Аерым алганда, балалар һәм яшьләр сәләтенә ярдәм күрсәтүдә Европа берлеге илләренең роле сизелерлек.

Сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр белән эшләүдә дәүләтнең катнашуы дәрәҗәсенә карап, ике төрле мөнәсәбәт аерып күрсәтелә – үзәкләштерелгән һәм үзәкләштерелмәгән.

Үзәкләштерелгән мөнәсәбәткә яшьләрнең җәмгыятьнең иҗтимагый-сәяси һәм социаль-икътисадый тормышына интеграцияләнүе өчен дәүләтнең җаваплылыгы нык регламентлану хас. Бу вакытта дәүләт сәләтле балалар һәм яшьләр белән эштә дә өстенлекләр билгели.

Мәсәлән, Кытайда мондый эшчәнлек тулысы белән Кытай Коммунистлар партиясе карарларына туры китереп гамәлгә ашырыла, монда яшьләрне икътисадый-хезмәт эшчәнлегенә җәлеп итүгә аерым игътибар бирелә.

Японияда бу эш дәүләт органнарының һәм җәмәгать институтларының үзара файдалы уртак гамәлләре һәм алар арасында җаваплылыкны төгәл бүлү нигезендә оештырыла. Махсус яшьләр үзәкләре, бюросы һәм хезмәтләре эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тәэмин итү киң кулланыла. Японияннең талантлар тәрбияләү институты, балаларны яшьли үстерү программалары эшли. Патентлар бюросы балаларның уйлап табучылар клублары эше өчен җавап бирә.

Сингапурда, интеллектуаль элитаны яңарта бару теориясен милли идеягә әйләндереп, «дөньяда иң яхшы милләт» тәрбияләргә тырышалар. Сәләтле (талантлы) кешеләр дәүләтнең һәм җәмгыятьнең тормыш эшчәнлеге өлкәсенең әйдәп баручы институтларын җитәкләргә тиеш. Монда сәләтле балалар белән эш илнең үзен уңышлы үстерү белән бәйләп карала.

Германиядә тормышка ашырыла торган гамәлләр стратегиясе барлык яшьләр файдалана ала торган социаль программа-

лар эшләүгә юнәлдерелгән. Барлык эре шәһәрләрдә яшьләрнең мәгълүмати үзәкләре эшли. 16 җирлекнең һәркайсында сәләтле балаларга һәм яшьләргә белем бирү һәм аларны педагоглар белән тәэмин итү программалары турындагы үз нигезләмәләре бар. Тикшерү һәм мониторинг программалары һәм проектлары эшли (яшьләрнең 30 ар мең вәкилен ел саен тикшерәләр, ә 900 кешене 3 әр ел күзәтәләр). Сәләтле студентларга матди ярдәм күрсәтелә.

Канадада мәктәпкә барыр алдыннан бер ел мәҗбүри рәвештә балалар бакчасына йөрү кертелгән.

Үзәкләштерелмәгән мөнәсәбәткә дәүләтнең ролен чикләү һәм әлеге функцияләрне иҗтимагый һәм коммерция секторына тапшыру хас. Бу эшчәнлектә алар тигез хокуклы нигездә катнаша. Бу мөнәсәбәт нигездә актив яшьләр өчен мөмкинлекләр тудыруга юнәлдерелә.

АКШта нык регламентланган шартларда дәүләт ярдәменә бары тик яшьләрнең социаль якланмаган категорияләре генә өмет итә ала. Сәләтлеләргә ярдәм күрсәтә торган программаларны һәм проектларны тормышка ашыруда катнашу өчен актив рәвештә коммерция секторы җәлеп ителә, тиешле механизмнар кертелә. Сәләтлелекне хуплау һәм үстерү буенча үтемле система булдырылган. Белем бирү буенча техник чаралар индустриясе үсеш алган. Һәр штатта сәләтләр буенча экспертларның махсус төркемнәре булдырылган. 140 тан артык университет сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр өчен махсус программалар тәкъдим итә.

АКШта сәләтле балалар белән эшләү буенча белем бирү тәҗрибәсе, Израильдәге, Тайваньдагы, Кореядагы кебек үк, интеллектны һәм креативлылыкны үстерү технологиясен үз эченә ала.

АКШта 1988 елда сәләтле (талантлы) балаларга ярдәм күрсәтү мәнфәгатьләреннән чыгып махсус эшләнгән «Джавитс» федераль программасы балаларның сәләтлелеге өлкәсендә тикшеренү проектларын һәм инновацион стратегияләрне координацияләү бурычларын хәл итә, башлангыч һәм урта мәктәптә эшнең нәтиҗәлелеген арттыруга йөз тота. Сәләтле мәктәп укучылары өчен укытучылар квалификациясенә карата рәсми таләпләр расланган.

Британия системасы яшь кешеләргә шанс (ярдәм) бирә, әмма мөстәкыйль активлыкка карата стимулны бозарга, иждивениегә китерергә мөмкин булган чамадан тыш опекадан кача. Шул ук вакытта сәләтле балаларны ачыклау – тулаем укуукыту процессының бер өлеше. Илкүләм программага карата

күрсәтмәләр нигезендә һәр мәктәптә һәм көллияттә якынча 5 процент күләмендә 11-19 яшьләрдәге сәләтле укучы ачыклана (якынча 10 проценты мәктәп тарафыннан сәләтле һәм талантлы балалар һәм яшьләр исемлегенә кертелергә мөмкин). Бәләкәйрәк чакта сәләтлелекне ачыклау максималь үзгәрүчән характерда булуны һәм сәләтле балаларны нәтиҗәле ачыклау өчен шартлар тудыруга, шулай ук сәләтле балалар категориясенә кертү һәм аннан чыгару өчен объектив механизм формалаштыруга ярдәм итүне билгеләп үтәргә кирәк.

Күрсәтелгән дәүләтләрдә сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр, аларның ата-аналары һәм педагоглары белән эшне координацияли торган җәмәгать оешмалары (Милли ассоциацияләр) эшләп килә.

Шул ук вакытта сәләтле балалар һәм яшьләр белән эш оештыруда дәүләтнең роле дә арта. Мәсәлән, Бөекбритания мәгариф департаменты 2007 елда «Сәләтлеләр һәм талантлылар» илкүләм проектын эшләде. Проект белем бирү стандартлары системасыннан, шулай ук сәләтле балалар белән эшләүче укытучылар өчен консультацияләр үткәрүдән гыйбарәт.

Швеция системасы проблемаларны, дәүләтнең тулы хокуклы партнерлары булган җәмәгать оешмаларын киң җәлеп итеп, хакимиятнең кайсы дәрәҗәсендә нәтиҗәле хәл итеп була, шул дәрәҗәсендә хәл итүгә юнәлдерелгән.

Сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр белән эшләү механизмнары төрле булуга да карамастан, алга киткән илләрнең күпчелеге өчен түбәндәгеләр уртак булып тора:

сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча хөкүмәт өчен дә, төрле учреждениеләр һәм ата-аналар өчен дә тәкъдимнәр эшли торган дәүләт һәм иҗтимагый экспертлар үзәкләре булу;

тиешле программалар эшләүдә һәм тормышка ашыруда дәүләт һәм җәмәгать һәм (яки) коммерция оешмалары арасында партнерлык булу.

### Россия Федерациясендә сәләтле (талантлы) балаларны һәм яшьләрне ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү

Россия Федерациясендә бу эшкә карата ике төрле мөнәсәбәт күзәтелә:

һәр төбәктә өлеше күп булмаган сәләтле балалар һәм яшьләр төркемен ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү – гадәти һәм иң аз чыгымнар сорый торган мөнәсәбәт;

белем бирү процессын индивидуаль белем бирү траекторияләренә таба юнәлдерү, бу – сәләтле балаларны һәм яшьләрне сайлап алырга гына түгел, шулай ук эшчәнлекнең төрле өлкәләрендә талантларны күпләп күрсәтү өчен шартлар тудыруга ярдәм итә – бу мөнәсәбәт массакүләм белем бирүнең йөзен үзгәртергә тиеш, әмма ул шактый зур финанс чыгымнары таләп итә.

Икенче мөнәсәбәтне тормышка ашыру профильле һәм тирәнтен белем бирүнең вариатив формаларын кертү аша алып барыла. Гомуми белем бирү системасында бу – азкомплектлы мәктәпләрдә, гимназияләрдә, лицейларда, авылларның база мәктәпләрендә челтәр аша үзара хезмәттәшлек итү нигезендә профильле сыйныфлар ачу, шулай ук мәктәп компоненты сәгатьләре кысаларында белем бирүнең индивидуаль-төркем траекторияләрен төзү. Өстәмә һәм махсус белем бирү учреждениеләре системасында – спорт, музыка һәм сәнгать мәктәпләрендә, сәнгать училищеларында, сәнгать һәм олимпия резервы училищеларында белем бирү.

Илебездә төрле белем бирү фәннәре буенча олимпиадалар форматында балалар арасында конкурс чараларын үстерүгә традицион рәвештә зур игътибар бирелә. Россия буенча балаларның 40 процентыннан артыгы төрле конкурсларда һәм олимпиадаларда катнаша. Аерым алганда, ил буенча Бөтенроссия олимпиадаларында мәктәп дәрәҗәсендә – укучыларның 32 проценты, муниципаль дәрәҗәдә – 9,5 проценты һәм төбәк дәрәҗәсендә 1,04 проценты катнаша.

Федераль дәрәҗәдә сәләтле (талантлы) балаларга һәм яшьләргә ярдәм күрсәтү эшен оештыру өчен җаваплылык үзеге булып соңгы вакытта әлеге проблемага карата игътибарын шактый көчәйткән Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тора. Россия Федерациясе төбәкләре эшчәнлеген анализлау аларның күбесендә сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләрне ачыклау мәсьәләләрендә, беренче чиратта, сәләтле (талантлы) балаларны һәм яшьләрне эзләү һәм аларга ярдәм күрсәтүнең аерым юнәлешләре буенча шактый эшләр башкарылуны күрсәтә.

Мәсәлән, «Сәләтле балалар» максатчан программалары һәм ярдәмче программалары Белгород, Брянск, Воронеж, Тула һәм Ярославль өлкәләрендә кабул ителде.

Самара, Ярославль, Новосибирск өлкәләрендә һәм Забайкалье краенда, сәләтле (талантлы) балалар белән эшләү үзенчәлеген (кече төркемнәр, индивидуаль остазлык, профиль-

лек) исәпкә алып, җан башына исәпләнгән нормативны хисаплап чыгару методикасына һәм хезмәт өчен түләүнең яңа системасын хисаплап чыгару методикасына төзәтмәләр кабул ителгән.

Күп төбәкләр сәләтле (талантлы) балаларны һәм яшьләрне олимпиадалар, ярышлар, фестивальләр һәм конкурслар системасы аша эзләүгә һәм сайлап алуга йөз тота, аларга күп санда укучылар җәлеп ителә. Федераль стипендияләргә, грантларга, премияләргә өстәп, төбәк, муниципаль стипендияләр, грантлар, премияләр гамәлгә куела.

Сәләтле балалар белән эшли торган учреждениеләр челтәрен: президент лицейларын, фәнни-тикшеренү үзәкләре базасында интернат-мәктәпләр һәм мәктәпләр, ресурс үзәкләре булдыруга аерым игътибар бирелә. Аерым алганда, Кемерово өлкәсендә талантлы балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча 4 төбәк һәм 28 муниципаль үзәк оештырылган. Мондый учреждениеләр оештыру сәләтле балаларның чикле төркемнәрен гомуми белем бирү мәктәбеннән махсуслаштырылган учреждениеләргә күчерүгә дә, гомуми белем бирү мәктәпләрендә махсус шартлар тудыруга да (өстәмә мөмкинлекләр, җәйге профильле сменалар, индивидуаль планнар, консультацияләр, дистанцион белем бирү) нигезләнә.

Федераль университетлар каршында сәләтле балаларга ярдәм күрсәтү үзәкләре һәм милли тикшеренү университетлары каршында дистанцион мәктәпләр оештырыла. Мәскәү физика-техника институты (дәүләт университеты), «МИФИ» милли тикшеренү атом-төш университеты, Н.Э. Бауман исемендәге Мәскәү дәүләт техник университеты каршында өстәмә белем бирү учреждениеләре эшли. Мәскәү шәһәренең 50 дән артык югары уку йорты Мәскәү балалар иҗат сарае белән хезмәттәшлек итә.

Сәләтле балаларга ярдәм күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне закон чыгару юлы белән хәл итү мисаллары да бар. Новгород өлкәсендә «Уку һәм фәнни-тикшеренү эшчәнлегендә сәләтләрен күрсәткән укучыларга социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә чаралар турында» 2010 елның 30 июлендәге 800-ОЗ номерлы Новгород өлкәсе законы кабул ителгән. Иркутск өлкәсендә «Иркутск өлкәсендә мәдәнияткә дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2007 елның 29 декабрендәге 154-ОЗ номерлы Иркутск өлкәсе законы гамәлгә ашырыла, аның кысаларында сәнгать өлкәсендә сәләтле балаларга һәм талантлы яшьләргә дәүләт ярдәме күрсәтелә.

Күп төбәкләр тиешле озак вакытлы максатчан төбәк программаларын кабул итүне планлаштыра. Аерым алганда, Әстерхан өлкәсендә норматив хокукый актлар пакетын кабул

итү планлаштырылган. Болар берничә ведомство нигезләмәләре (интеграцияләнгән авторлык белем бирү программаларын эшләү турында; балаларның белем алудагы компаратив югары казанышларын сертификатлау буенча төбәк системасы хакында; индивидуаль белем бирү маршрутлары траекторияләре турында; интеграцияләнгән технологияләр һәм консалтинг-тьюторлык методикалары буенча педагогик кадрлар әзерләүгә карата таләпләр). Әстерхан өлкәсе Хөкүмәтенең белем алуда компаратив югары казанышлары булган балигъ булмаганнарга дәүләт ярдәме күрсәтү һәм аларны стимуллаштыру чараларын (шул исәптән аларны «яшьтән үк» производство предприятиеләренә, фәнни эшләнмәләргә, социаль, идарә итү өлкәләрендәге һәм казанышларның башка өлкәләрендәге стажировкаларга беркетү буенча) тәртипкә сала торган «Гомуми белем бирү учреждениеләренең талантлы укучыларын бүләкләү турында» 2009 елның 16 июнендәге 291-П номерлы карары кабул ителде.

Күп төбәкләрдә сәләтле балалар һәм яшьләрнең һәм алар белән эшләүче педагогларның мәгълүматлар базасы формалаштырыла. Шул ук вакытта алар тормышта аз кулланыла.

Воронеж, Мәскәү, Самара өлкәләрендә, Красноярск, Пермь крайларында һәм башка төбәкләрдә модульле программалар нигезендә сәләтле балалар һәм яшьләр белән эшкә әзерләү буенча педагоглар квалификациясен күтәрү тәҗрибәсе булу күренеп тора.

Тулаем алганда «Мәгариф» өстенлекле илкүләм проектын, «Сәләтле балалар» ярдәмче программасын, «Яңа мәктәбебез» милли мәгариф башлангычын тормышка ашыру сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр белән эшне камилләштерү өчен яхшы алшартлар тудыра.

Шул ук вакытта инде гамәлдә булган дәүләт программаларының нәтиҗәлелеген киметә торган кайбер сәбәпләрне аерып күрсәтергә һәм эштә исәпкә алырга кирәк.

Аларның берсе – программаларның декларатив булуы. Алар, кагыйдә буларак, сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләрнең индивидуаль үзенчәлекләрен һәм аермалыкларын исәпкә алмый һәм игътибарны нәтиҗәлелеккә түгел, күбрәк хисаплылыкка юнәлдерә.

Шулай ук сәләтле балалар һәм яшьләрне ачыклау чараларының предмет диапазоны тар булу билгеләп үтелә. Еш кына болар мәктәп фәннәре. Индивидуаль эш нәтиҗәсендә алынган креативлык, яңа идеяләр яки белемнәр һәм күнекмәләр бәяләнми. Моның аркасында күп кенә потенциаль талантлар

ачылмый кала. Моңа шулай ук сәләтле балалар һәм яшьләрне ачыклау инструментларының камил булмавы да ярдәм итә.

Балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерүгә һәм тормышка ашыруга йогынты ясый торган тискәре фактор булып балаларны «сәләтлеләргә» һәм «сәләтсезләргә» (күп очракта күзгә күренеп тормаган) аеру белән чамадан тыш мавыгу тора. «Сәләтлеләр» категориясенә кертелмәгән яшь кешеләр белем алуга мотивациясен югалта. Сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр әйләнә-тирәдәгеләрнең чамадан артып киткән өметләре йөген үз өсләрендә йөртергә тиеш була. Шуның өстенә сәләтле балалар һәм яшьләр өчен уку-укыту программаларының «үзгәрүчән» булмавы да билгеләп үтелә.

## Татарстан Республикасында сәләтле (талантлы) балаларны һәм яшьләрне ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү

Татарстан Республикасына тулаем алганда гомумроссия тенденцияләре хас. Сәләтле (талантлы) балаларга һәм яшьләргә ярдәм күрсәтү эшен оештыру буенча җаваплылык үзәге булып үз эшен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы белән бергәләп алып баручы Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы тора.

Татарстан Республикасында сәләтле балаларга булышлык күрсәтүгә кагыла торган берничә максатчан программа тормышка ашырыла, шулай ук талантлы яшьләргә дәүләт ярдәме күрсәтү чараларын билгели торган норматив хокукый актлар кабул ителде. Аерым алганда, бу Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2011-2013 елларга «Татарстан балалары» озак вакытлы максатчан программасын раслау турында» 2010 ел, 30 декабрь, 1150 нче карары белән расланган 2011-2013 елларга Татарстан балалары» озак вакытлы максатчан программасының «Сәләтле балалар» ярдәмче программасы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Мәгариф» өстенлекле милли проектын тормышка ашыру турында» 2006 ел, 17 май, 249 нчы карары. Татарстан Республикасы сәләтле (талантлы) балаларга һәм яшьләргә ярдәм күрсәтү гамәлләрен финанслау буенча Россия Федерациясенең лидер төбәкләре төркеменә керә.

Кагыйдә буларак, балалар һәм яшьләрнең сәләтләре нәтиҗәләренең рейтингы билгеләнә торган төрле ачык интеллек-

туаль конкурсларда, конференцияләрдә, олимпиадаларда, турнирларда, күргәзмәләрдә, иҗади конкурсларда, фестивальләрдә һәм спорт ярышларында ачыклана һәм бәяләнә.

Укучыларның иҗади, танып белү һәм интеллектуаль башлангычын активлаштыру максатыннан чыгып, түбәндәге чаралар үткәрелә: Идел буе укучылар фәнни экология конференциясе, Н.И.Лобачевский исемендәге Идел буе укучылар фәнни конференциясе, «Интеллект» төбәк фәнни-техник олимпиада-конференциясе, «XXI гасыр Кулибиннары» республика яшь уйлап табучылар олимпиадасы, «Химик бум» телеуен-олимпиадасы, «Эрудит» конкурсы, Мәктәп компанияләре слеты һәм башкалар. Ел саен аларда республикадан һәм башка төбәкләрдән 2,5 меңнән артык укучы катнаша.

Республика муниципаль берәмлекләренең күпчелегендә мәктәп фәнни җәмгыятьләре эшли, аларда ел саен 20 меңнән артык бала шөгыльләнә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 30 декабрь, 1174 нче карары белән расланган 2010-2015 елларга Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү буенча «Киләчәк» – «Будущее» стратегиясен тормышка ашыру кысаларында электрон белем бирүнең төрле формалары актив кертелә, перспективалы белем бирү ресурслары һәм технологияләре файдаланыла. Махсуслаштырылган гимназияләр һәм лицейлар үсеш ала, сәләтле балалар өчен интернат тибындагы республика мәктәбен оештыру эше алып барыла.

Татарстан Республикасының Мәгарифне үстерү институты базасында педагог хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү буенча «Сәләтле балалар белән эшләү чаралары комплексын эшләү» курслары үткәрелә.

Берничә ел дәвамында әйдәп баручы югары уку йортлары катнашында сәләтле укучылар өчен «Квант», «Биосфера» һәм «Лингво-Лидер», (Казан (Идел буе) федераль университеты базасында), «Орбиталь» (Казан милли тикшеренү технология университеты (КХТИ) базасында), «Интеллект» (А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ базасында) профильле лагерьлары, «Байтик» компьютер лагере эшли.

Казан (Идел буе) федераль университеты, А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ, Казан милли тикшеренү технология университеты каршындагы кече университетларда белем бирү процессы тагын да югарырак дәрәҗәдә тормышка ашырыла, аларда югары һөнәри

белем бирү учреждениеләре укытучылары тарафыннан сәләтле балалар һәм яшьләр белән эш алып барыла.

«Сәләт» хәрәкәтенең сәләтле яшьләре үткәрә торган лагерьлар һәм проектлар уңыш казана, ел саен аларда 2 меңгә якын бала була.

Соңгы берничә ел дәвамында Бөтенроссия олимпиадалары нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы укучылары командасы Идел буе федераль округы буенча лидер булып тора һәм Россиядә иң яхшы командаларның берсе позициясен нык тота. 2010 елда Татарстан Республикасының 14 мәктәп укучысы Бөтенроссия олимпиадасында җиңде һәм 45 мәктәп укучысы призер булды. Республика буенча олимпиадаларда мәктәп дәрәҗәсендә барысы бергә 150 меңгә якын, муниципаль дәрәҗәдә 42,5 меңгә якын һәм республика дәрәҗәсендә 3,3 меңгә якын укучы катнашты.

2011 елда 14 укучы Бөтенроссия олимпиадасында җиңде һәм 61 укучы призер булды. 2011 елда халыкара олипиадаларда һәм конкурсларда ясаган чыгышлар йомгаклары буенча 1 укучы Математика буенча халыкара олимпиадада җиңүче, 1 укучы – астрофизика буенча V Халыкара альтернатив олимпиадада бронза призеры, 2 укучы – Су проектлары буенча халыкара конкурс финалисты, 1 укучы Intel ISEF халыкара ярминкәсе финалисты булды.

Мәктәп укучыларының Бөтенроссия һәм халыкара олимпиадалары йомгаклау этабында җиңүчеләрне һәм призерларны Татарстан Республикасында беркетү өчен көндезге формада белем алучы студентларга 100 махсус стипендия гамәлгә куелды.

Республика муниципаль районнарының күпчелегендә талантлы яшьләрне кызыксындыру өчен грантлар, стипендияләр, бер тапкыр бирелә торган премияләрне гамәлгә куюга финанс чаралары бүлеп бирелә.

Сәләтле яшьләргә бизнес-структуралар ягыннан ярдәм күрсәтү чаралары үткәрелә. Мәсәлән, 2009 елдан башлап, республикада «Русский стандарт» хәйрия фонды укуын дәвам иттерү һәм үз сәләтләрен үстерү өчен 14 яшьтән 20 яшькә кадәрге талантлы яшьләргә финанс ярдәме күрсәтү программасын тормышка ашыра. «Татфондбанк» акционер инвестиция коммерция банкы» ачык акционер җәмгыяте тарафыннан «Авылның 100 талантлы баласы» озак вакытлы программасы тормышка ашырыла. Аеруча талантлы студентларны бүләкләү өчен «АК БАРС» БАНК ачык акционер җәмгыяте тарафыннан исемле стипендияләр булдырыл-

ды. «Татнефть» ачык акционер җәмгыятенең «Сәләтле балалар» хәйрия фонды тарафыннан зур эш алып барыла.

Сәләтле балаларны һәм талантлы яшьләрне эзләү һәм аларга ярдәм күрсәтү, аларның иҗади потенциалын үстерү өчен уңайлы мохит булдыру һәм шартлар тудыру буенча әйдәп баручы чаралар булып ел саен үткәрелә торган халыкара, Бөтенроссия һәм төбәк фестивальләре һәм конкурслары тора. Бу, иң беренче чиратта, «Созвездие – Йолдызлык», «Весенние выкрутасы», «Молодые дарования России», «Джазовая капель», «ТАТ-ARS-ТАН», «Татарстан фанфаралары», «Алтын каләм – Золотое перо» һәм башкалар. Яшь талантлар өчен махсус стипендияләр билгеләнә.

Спорт өлкәсендә талантлы балаларны ачыклау системасы һәм махсуслаштырылган учреждениеләр челтәре үсә. Республика чемпионатлары һәм спартакиадалары үткәрелә. Бөтенроссия һәм халыкара дәрәҗәдәге ярышларда катнашучыларга максатчан ярдәм күрсәтелә. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы спортчыларына һәм тренерларына дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2010 ел, 19 гыйнвар, 17 нче карары нигезендә махсус айлык стипендияләр гамәлгә куелды.

Яшь галимнәргә һәм белгечләргә дәүләт ярдәме күрсәтү максатларында грантлар, премияләр, махсус стипендияләр булдырылды, М.И.Лобачевский исемендәге премия алу өчен студентлар һәм аспирантларның фәнни эшләре еллык республика конкурсы үткәрелә, шулай ук «50 иң яхшы инновацион идея», «Старт-1», «Старт-2», «Идея-1000», «У.М.Н.И.К.», «Әйдәп баручы фәнни мәктәпләр» кебек программалар эшләп килә.

Үз илебезнең һәм чит илләрнең әйдәп баручы фәнни-белем бирү үзәкләрендә яңадан әзерлек алу һәм стажировка үтү буенча «Алгарыш» программасы аерым роль уйный, аны тормышка ашыруга ел саен 100 млн.сумга кадәр акча җибәрелә.

«Кадрлар резервы», «Югарыга» яшьләр конкурслары, яшьләрнең инновацион форумнары үзләрен уңай яктан күрсәтте, алар сәләтле яшьләрне ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү өчен үтемле мәйданчыкларга әйләнде.

Шул ук вакытта, сәләтле балалар һәм яшьләр белән эшләүдә билгеле бер казанышлар булуга да карамастан, берничә проблемалы мәсьәләне аерып күрсәтергә була.

Сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр турындагы мәгълүматлар төрле структуралар буенча таралган, яшьләрнең мондый категориясе өчен махсуслаштырылган мәгълүмат ре-

сурслары юк, болар үткәреләә торган конкурслар, фестивальләр, төрле дәрәҗәдәге олимпиадалар турында тулы күләмдә мәгълүмат алырга комачаулый.

Эш ведомстволар арасында координацияләнми, инде гамәлдә булган формалар сәләтле шәхесне үстерү буенча аны күреп алган вакыттан башлап аның нинди дә булса формада реализацияләнүенә кадәр (белгечлек буенча эшкә урнашу, үз бизнесын булдыру, индивидуаль, фәнни, иҗади яки спорт карьерасын үстерү) «эзлекле рәвештә кызыксынып тору» кебек бердәм система тәшкил итми.

Бөтенроссия олимпиадаларында, грант программаларында җиңүчеләрнең һәм бүләкләнүчеләрнең күбесе белем алуын Татарстан Республикасыннан читтә дәвам иттерергә омтыла, бу, беренче чиратта, аларның үз максатларына ирешү өчен мөмкинлекләр һәм индивидуаль карьераны үстерү өчен перспективалар зур булуга бәйле.

Бүген сәләтле балалар һәм яшьләр белән эшләүче квалификацияле кадрлар, педагоглар, психологлар һәм башка белгечләр әзерләү, яңадан әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү буенча эшләп торучы программалар җитәрлек түгел. Шулай ук бу эшкә квалификацияле фәнни җитәкчелек һәм методик яктан тәэмин итү дә җитәрлек түгел. Балалар һәм яшьләрнең иҗади сәләтләрен үстерүгә юнәлдерелгән белем бирү технологияләреннән күпләп файдалану тәҗрибәсе дә юк.

Кагыйдә буларак, өстәмә белем бирү учреждениеләренең матди-техник базасы (аеруча авыл җирендә) түбән дәрәҗәдә булу, шулай ук норматив-җан башы буенча финанслау кысаларында махсус финанслау нормативлары булмау билгеләп үтелә.

Югары һөнәр белеме бирү учреждениеләренең һәм фәнни-тикшеренү институтларының укытучылар һәм фәнни кадрларын остазлар (тьюторлар) сыйфатында җәлеп итү, югары уку йортлары лабораторияләреннән һәм академик лабораторияләрдән сәләтле яшьләрнең инновацион эшләнмәләрен үстерү буенча старт мәйданчыклары сыйфатында файдалану кебек дөньяда үзен яхшы яктан күрсәткән эш формалары тиешле дәрәҗәдә файдаланылмый.

Шулай ук иҗтимагый һәм коммерция секторларын сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр белән эшләү өчен җәлеп итүнең йомшак куелуын билгеләп үтәргә кирәк.

Түбәндә китерелгән таблицада сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр белән эшләүнең хәзерге хәленең төп көчле һәм

йомшак яклары, Концепциянең аны эшләгәндә исәпкә алынган мөмкинлекләре һәм куркыныч янаулары бәян ителгән:

| Көчле яклары | Йомшак яклары |
|---|---|
| республика үсешенең инновацион векторы, үсеш алган инфраструктура (технопарклар, фәнни һәм белем бирү учреждениеләре, югары технологияле производстволар һ.б.);<br>2010-2015 елларга Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү буенча «Киләчәк» – «Будущее» стратегиясе булу;<br>мәгарифкә, балалар һәм яшьләр белән эшләүгә җибәреләторган финанс ресурсларының күләме зур булу;<br>сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләрне ачыклауның төрле механизмнары һәм формалары булу (олимпиадалар, конкурслар, грант программалары, стипендияләр һ.б.);<br>ачыклана торган сәләтле (талантлы) балаларның һәм яшьләрнең (шул исәптән Бөтенроссия һәм халыкара конкурсларда җиңүчеләрнең) саны күп булу;<br>республикада мәгълүмат технологияләре таралу дәрәҗәсе югары булу;<br>Татарстан Республикасындагы социаль һәм сәяси тотрыклылык | сәләтле (талантлы) яшьләрнең Татарстан Республикасыннан китүе;<br>инновацион инфраструктурадан файдалануның нәтиҗәсе түбән булу;<br>югары квалификацияле персонал сайлап алу һәм әзерләү механизмнары нәтиҗәле булмау;<br>белем бирү, беренче чиратта һөнәри белем бирү дәрәҗәсе түбән булу;<br>хезмәт базары диспропорциясе һәм яшьләргә үз һөнәри мөмкинлекләрен тормышка ашыру кыен булу;<br>«социаль лифтларның» нәтиҗәсе түбән булу;<br>куллану характерындагы социаль максатлар өстенлек алу, балаларның һәм яшьләрнең мөстәкыйльлеге һәм инициативасы түбән дәрәҗәдә булу;<br>чит телләрне начар белү, дөньякүләм фәнни-белем бирү киңлегенә интеграцияләнү дәрәҗәсе түбән булу;<br>сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча белгечләр җитешмәү;<br>идарә итү буенча социаль технологияләр, социаль инновацияләр үсеше түбән булу |

| Мөмкинлекләр | Куркыныч янау |
|---|---|
| икътисадның фәнни казанышлар кергән секторларын үстерү;<br>эш бирүчеләрнең югары квалификацияле кадрларга ихтыяҗы арту;<br>мәгълүмат-коммуникация мохите киңәю, шул исәптән яңа белемнәр алу мөмкинлеге;<br>гражданлык җәмгыяте институтлары үсү;<br>халыкара элемтәләр һәм партнерлык мөнәсәбәтләре киңәю, Татарстан Республикасының динамикалы үсүче төбәк буларак уңай имиджы үсү;<br>сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләргә ярдәм күрсәтү мәсьәләләрен хәл итүгә карата сәяси ихтыяр булу | икътисадта чимал өлеше зур булып калу;<br>әйдәп баручы фәнни-белем бирү үзәкләре һәм уңышлы үсә торган төбәкләр ягыннан конкуренция арту, республикадан сәләтле (талантлы) яшьләр китү темплары арту;<br>эшнең бербөтен системасы булмау, сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләрне ачыклау, үстерү һәм алар белән кызыксынып торуны, шул исәптән эшкә урнаштыруны ведомствоара координацияләү түбән дәрәҗәдә булу;<br>тискәре мәгълүматның артык күп булуы һәм яшьләрнең аңы белән манипуляцияләү мөмкинлеге;<br>сәләтле (талантлы) балаларны һәм яшьләрне ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү буенча норматив хокукый база камил булмау |

## 2. Концепциянең максатлары, бурычлары һәм принциплары

Концепциянең максаты – Татарстан Республикасының конкурентлык өстенлекләрен арттыруның нигезе буларак балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын нәтиҗәле үстерү һәм тормышка ашыру буенча бердәм республика системасы булдыру.

Концепциянең бурычлары:

1. Эшчәнлекнең төрле өлкәләрендә сәләтле (талантлы) балаларны һәм яшьләрне ачыклау.

2. Сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр турындагы мәгълүматлар базасын булдыру һәм актуаль хәлдә тоту.

3. Сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр компетенцияләрен формалаштыру һәм сәләтләрен үстерү.

4. Сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр белән эзлекле рәвештә кызыксынып тору, аларны иҗади эшчәнлеккә җәлеп итү.

5. Мәгълүмат-коммуникация мохитен, шул исәптән махсуслаштырылган республика порталын формалаштыру.

6. Сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләрне Татарстан Республикасында беркетү һәм республикага җәлеп итү, аларга үз мөмкинлекләрен тормышка ашыру, эшкә урнашу һәм һөнәри яктан үсү өчен уңай шартлар тудыру.

7. Сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр белән эш алып баручы, шул исәптән махсуслаштырылган учреждениеләр челтәрен киңәйтү. Аларның эшчәнлеген кадрлар белән тәэмин итү.

8. Иҗтимагый формированиеләр, шул исәптән Татарстан Республикасын инновацион үстерүгә йөз тоткан яшьләр берләшмәләре барлыкка килүне стимуллаштыра торган механизмнар булдыру.

9. Фәнни-тикшеренү эшен оештыру, сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча перспективалы модельләр эшләү һәм кертү.

10. Перспективалы яшьләр башлангычларын һәм проектларын мониторинглау һәм аларга максатчан ярдәм күрсәтү.

11. Эшчәнлекнең төрле юнәлешләре буенча кадрлар резервын формалаштыру.

12. Эшне ведомствоара координацияләүне, интеллектуаль, финанс һәм оештыру көчләрен балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерүгә һәм тормышка ашыруга, үзара хезмәттәшлекнең челтәр эчендәге механизмнарын үстерүгә туплауны тәэмин итү.

Концепция түбәндәге төп принципларга нигезләнә:

1. База мөмкинлекләре тигез булу принцибы.

30 яшькә кадәрге барлык балалар һәм яшьләрне, шулай ук яшь (35 яшькәчә) галимнәрне һәм аспирантларны, аларның яшәү урыннары кайда һәм социаль-икътисадый хәлләре нинди булуга карамастан, ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү буенча бердәм төбәк системасында катнашу һәркем өчен мөмкин булуга нигезләнә.

Барлык катнашучылар өчен тигез мөмкинлекләр һәм уртак таләпләр күздә тотыла.

2. Системалылык принцибы.

Концепция бурычларына ирешүдә системалы мөнәсәбәт эшнең төп факторларын һәм юнәлешләрен җыелма исәпкә алуны, инновацион һәм белем бирү инфраструктурасының барлык звенолары эшчәнлеген координацияләүне, дәүләтнең, эш бирүчеләрнең, җәмәгатьчелекнең, балалар һәм яшьләрнең үз мәнфәгатьләрен исәпкә алуны күздә тота.

Субъектлар арасында төзелә торган мөнәсәбәтләр уртак бурычлар белән үзара бәйләнергә, системалы характерда булырга тиеш.

3. Индивидуаль мөнәсәбәт принцибы.

Яшь кешеләрнең шәхси потенциалын мөмкин кадәр нәтиҗәлерәк ачу максатыннан чыгып, ачыклана торган мәнфәгатьләр һәм сәләтләр, шулай ук Татарстан Республикасы үсешенең өстенлекләре нигезендә белем бирүнең, карьераның һәм үзлектән үсешнең индивидуаль траекторияләре эшләнә.

4. Социаль партнерлык принцибы.

Концепция балалар  һәм яшьләрнең индивидуаль иреге һәм социаль җаваплылыгы гармонияле ярашкан булу зарурлыгыннан чыга, бу вакытта шәхси һәм иҗтимагый мәнфәгатьләр бер-берсенә каршы килми, ә яшьләрнең үз мөмкинлекләрен тормышка ашыруы һәм Татарстан Республикасын үстерү  максатларында үзара бәйләнештә яраша.

5. Мәгълүмат аңлаешлы һәм ачык булу принцибы.

Балалар һәм яшьләр өчен концепцияне тормышка ашыру программаларында катнашу мөмкин, ачык һәм аңлаешлы була. Белем алу һәм фәнни мөмкинлекләр, яңадан әзерләү һәм квалификация күтәрү, эшкә урнашу һәм хәзерге заман үсешенең өстенлекле юнәлешләре буенча балаларга (аларның ата-аналарына), яшьләргә үз мөмкинлекләрен тормышка ашыруның төрле формалары турында мөмкин кадәр югары дәрәҗәдә тулы мәгълүмат җиткерү күздә тотыла.

Концепцияне тормышка ашыруның партнерлары һәм операторлары итеп төрле иҗтимагый структураларны һәм коммерция формированиеләрен киң җәлеп итү күздә тотыла. Бу принцип кызыксынучы барлык яклар өчен мәгълүматның ачык һәм һәркем файдалана алырлык булуына йөз тота, сәләтлелеккә булышлык күрсәтү буенча социаль теләкләрне тотрыклы формалаштыруга юнәлдерелә.

6. Кире элемтә принцибы.

Системаны хәзерге дөньяның һәрвакыт үзгәреп торучан шартларына һәм хезмәт базары таләпләренә яраклаштыру өчен Концепция белән кире элемтәнең катнашучыларга һәм партнер-

ларга сәләтле (талантлы) балаларны һәм яшьләрне ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү системасы эшенә йогынты ясарга, аны камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертүгә ярдәм итә торган даими эшләп торучы механизмнары күздә тотыла.

7. Эшчәнлек аша якын килү принцибы.

Бу принцип белем бирү һәм тәрбия процесслары эшчәнлек барышында аеруча уңышлы уза дигән фикердән чыга. Концепцияне тормышка ашырганда бу принципны исәпкә алу балалар һәм яшьләрнең сәләтләрен нәтиҗәле ачыклауга һәм үстерүгә, аларның үз мөмкинлекләрен уңышлы тормышка ашыруга ярдәм итәргә тиеш.

## 3. Концепцияне гамәлгә ашыру механизмнары

Татарстан Республикасы Президенты Концепцияне гамәлгә ашыру буенча ведомствоара координация советын (алга таба – Ведомствоара координация советы) төзи, аның турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслый.

Ведомствоара координация советы Концепцияне гамәлгә ашыру һәм моның өчен кирәкле ресурслар җәлеп итү буенча тәкъдимнәр эшли, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, Концепцияне тормышка ашыруда катнашучы оешмалар һәм учреждениеләрнең үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә, шулай ук сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр белән эшне камилләштерү буенча Татарстан Республикасы Президентына башка тәкъдимнәр кертә, Концепциягә үзгәрешләр кертү башлангычы белән чыга.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Концепцияне тормышка ашыру буенча республика максатчан программасын эшли һәм раслый, аны үтәү вакытларын һәм ресурслар белән тәэмин ителешен билгели, шулай ук Концепциянең төп нигезләмәләрен тормышка ашыруга юнәлдерелгән норматив хокукый актлар кабул итә.

Концепцияне тормышка ашыру буенча республика максатчан программасын үтәү эшен оештыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтле орган (махсуслаштырылган оешма) билгеләү турында карар кабул итә һәм аның эшчәнлеге өчен кирәкле шартлар тәэмин итә.

Вәкаләтле орган:

Ведомствоара координация советы карарларын үтәү эшен оештыра;

Концепцияне гамәлгә ашыру программаларын эшләү башлангычы белән чыга һәм аларның үтәлешен тәэмин итә, аларны сәләтле балалар һәм яшьләргә булышлык күрсәтү буенча республиканың башка программаларын гамәлгә ашыру белән синхронлаштыра;

Концепцияне тормышка ашыру бюджетын формалаштыру буенча тәкъдимнәр эшли;

Концепцияне тормышка ашыруны фәнни-гамәли яктан, шул исәптән экспертлар тарафыннан кызыксынып торуны тәэмин итә;

билгеләнгән тәртиптә сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләрнең шәхси мәгълүматлары базасын формалаштыра һәм аның белән идарә итә, Ведомствоара координация советына дәүләт, муниципаль идарә өлкәсе һәм Татарстан Республикасы икътисадының төрле секторлары өчен кадрлар резервы формалаштыру буенча тәкъдимнәр кертә;

махсуслаштырылган портал һәм мәгълүмати ресурслар эшчәнлеген тәэмин итә;

Концепцияне тормышка ашыру кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының, оешмаларның һәм учреждениеләрнең үзара хезмәттәшлеген оештыруда катнаша, эшчәнлекнең төрле юнәлешләре буенча партнерлар һәм операторлар билгели һәм алар белән килешүләр төзи;

перспективалы яшьләрне эшкә урнаштыру чараларын эшләү максатыннан чыгып, эш бирүчеләрне Концепцияне тормышка ашыруга җәлеп итүне тәэмин итә;

яшьләр башлангычларын һәм проектларын мониторинглауны һәм аларга ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыра;

кирәкле норматив хокукый документлар эшләү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр кертә.

Концепцияне тормышка ашыруда катнашучылар булып Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, Концепция максатларына һәм бурычларына теләктәш булган һәм балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын ачыклау, үстерү һәм тормышка ашыру эшчәнлегендә турыдан-туры катнашучы учреждениеләр, оешмалар, берләшмәләр һәм физик затлар тора.

Югарыда күрсәтелгән субъектлар вәкаләтле орган белән тиешле килешү төзегәндә эшчәнлекнең һәм аны үтәү чараларының

төрле юнәлешләре буенча Концепцияне тормышка ашыру партнерлары, операторлары була.

Концепцияне тормышка ашыруда мөһим механизм булып Концепцияне тормышка ашыруда катнашучы барлык субъектларның күпкырлы эшен чагылдырачак, Концепциянең төп юнәлешләре буенча уңайлы һәм нәтиҗәле интерфейслар булдырачак, яшьләр өчен кызыклы һәм актуаль булачак портал торырга тиеш.

## 4. Концепцияне тормышка ашыруның төп юнәлешләре

Концепциянең максатчан адресаты – «Татарстан Республикасында яшьләр һәм дәүләт яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә балалар һәм яшьләр, шулай ук яшь (35 яшькәчә) галимнәр һәм аспирантлар.

Балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын ачу сәләтлелекнең һәм (аларның берничәсе берләшүнең) төрле типларын ачыклауга, аларга ярдәм күрсәтүгә һәм алар белән кызыксынып торуга йөз тота, алар арасындагы төп типлар түбәндәгеләр:

интеллектуаль сәләт (фәнни-тикшеренү, инновация, предмет эшчәнлегендә күренә торган интеллектуаль үсеш дәрәҗәсе югары булу белән билгеләнә);

иҗади һәм сәнгати сәләт (сәнгати иҗат өлкәсендә, музыкада, сынлы сәнгатьтә, әдәбиятта, сәхнә эшчәнлегендә югары казанышларда күренә);

спортка сәләт (физик үсеш дәрәҗәсе һәм спортның төрле төрләрендә югары казанышлар белән билгеләнә);

социаль сәләт (иҗтимагый һәм эшкуарлык эшчәнлегендәге уңышлар, лидерлык һәм оештыру сәләтләре белән билгеләнә).

Концепцияне тормышка ашыруның төп юнәлешләре аның бурычларыннан чыга һәм аларны үтәү өстенлекләрен чагылдыра.

1. Эшчәнлекнең төрле өлкәләрендә сәләтле (талантлы) балаларны һәм яшьләрне ачыклау:

эшчәнлекнең төрле өлкәләрендә сәләтле (талантлы) балаларны һәм яшьләрне ачыклау буенча тиешле конкурс чараларын һәм методикаларын эшләү һәм камилләштерү;

дөньякүләм үсешнең иң яңа тенденцияләрен һәм Татарстан Республикасы үсешенең өстенлекле юнәлешләрен исәпкә алып, конкурс чараларын киңәйтү;

конкурс чараларына җәлеп ителгән балалар һәм яшьләр санын арттыру;

сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр белән эшләүче оешмалар һәм учреждениеләр эшчәнлеген мониторинглау һәм оптимальләштерү;

өстәмә белем бирү системасын, аның сәләтле (талантлы) балаларны һәм яшьләрне ачыклауга һәм аларга ярдәм күрсәтүгә юнәлгән булуын камилләштерү;

балаларны һәм яшьләрне конкурс эшчәнлегенә мөстәкыйль (оештырмыйча) кертү механизмнарын үстерү;

мәктәпкәчә белем бирүнең мәҗбүри сегментын кертү.

2. Сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр турындагы мәгълүматлар базасын булдыру һәм актуаль хәлдә тоту:

республика мәгълүматлар базасына кертү өчен сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләрне сайлап алу критерийларын һәм конкурс чаралары исемлеген билгеләү;

сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр турындагы мәгълүматлар исемлеген, норматив хокукый актлар эшләү һәм аларны җыюны регламентлаштыру;

алар буенча исәп алып барыла торган юнәлешләрне һәм җаваплылык үзәкләрен (министрлыкларны һәм ведомстволарны) билгеләү;

эшчәнлекнең төрле юнәлешләре буенча мәгълүматлар базасын формалаштыру һәм исәпкә алу системасын алып бару;

сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр рейтингларын алып бару һәм мониторинглау методикаларын эшләү һәм кертү.

3. Сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләрнең сәләтләрен үстерү һәм компетенцияләрен формалаштыру:

сәләтлелек типлары буенча сәләтле (талантлы) балаларга һәм яшьләргә диагностика үткәрү методикаларын һәм технологияләрен булдыру һәм камилләштерү;

эшчәнлекнең төрле юнәлешләре буенча компетенцияләрне үлчәү механизмнарын һәм аларны куллану технологияләрен, шул исәптән социаль тренажерлар эшләү;

эш бирүчеләр белән берлектә, төп һәм перспективалы белгечлекләр буенча компетентлык тасвирнамәләрен формалаштыру;

сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләрне үстерүнең индивидуаль траекторияләрен төзү технологияләрен эшләү;

сәләтлелек юнәлешләре һәм компетенцияләр төркемнәре буенча белем бирү, үсеш модульләрен булдыру;

эшчәнлекнең тар һәм перспективалы юнәлешләре буенча югары дәрәҗәле белгечләр җәлеп итеп, бер тапкыр үткәрелә торган һәм комплекслы чаралар үткәрү.

4. Сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр белән эзлекле рәвештә кызыксынып тору, аларны иҗади эшчәнлеккә тарту:

сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләрне барлык этапларда – сәләтне ачыклаудан алып эшкә урнашканга кадәр – күзәтеп тору механизмнарын булдыру;

индивидуаль үсеш траекторияләре үзенчәлеген саклап, сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләрнең бер учреждениедән икенче учреждениегә күчү технологиясен эшләү;

вәкаләтле орган, Концепциянең аерым юнәлешләрен тормышка ашыру операторлары (эшчәнлек юнәлешләре буенча) тарафыннан аларны гамәлгә ашыруда сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр катнашуны күздә тота торган тормышта куллануга юнәлдерелгән вариатив проект модульләрен һәм программаларын формалаштыру;

тьюторлык (остазлык) институтларын үстерү һәм консультация хезмәтләре күрсәтү.

5. Мәгълүмат-коммуникация мохитен, шул исәптән махсуслаш-тырылган республика порталын формалаштыру:

сәләтле (талантлы) балаларга һәм яшьләргә Татарстан Республикасында белем алу һәм үз мөмкинлекләрен тормышка ашыру, эшкә урнашу һәм һөнәри яктан үсү өчен киң мөмкинлекләр булу турында мәгълүмат бирү;

массакүләм мәгълүмат чараларында Концепцияне тормышка ашыруга кагыла торган актуаль мәсьәләләр буенча проектлар булдыру, сәләтле (талантлы) балаларга һәм яшьләргә ярдәм күрсәтүгә кагыла торган уңай социаль теләкләр формалаштыру;

сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләрнең Татарстан Республикасының төп фәнни-белем бирү һәм гамәли ресурсларыннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү;

дөньякүләм үсешнең иң яңа тенденцияләрен һәм Татарстан Республикасы үсешенең өстенлекле юнәлешләрен чагылдыра торган кызыклы мәгълүмати-танып белү ресурсларын булдыру;

конкурс, белем бирү һәм проектлау чараларының көндезгечиттән торып һәм дистанцион формаларын үстерү;

интеграцияләнгән рәвештә Концепцияне тормышка ашыручы барлык субъектлар эшчәнлеген чагылдыра һәм алар өчен кире элемтәне һәм челтәр эчендә үзара хезмәттәшлекне тәэмин итә торган махсуслаштырылган республика порталын булдыру;

сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр белән эшләүче белгечләргә һәм ата-аналарга консультация ярдәме күрсәтү.

6. Сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләрне Татарстан Республикасында беркетү һәм республикага җәлеп итү, аларга үз мөмкинлекләрен тормышка ашыру, эшкә урнашу һәм һөнәри яктан үсү өчен уңай шартлар тудыру:

Татарстан Республикасында һөнәр белеме алу һәм эшкә урнашу перспективасын исәпкә алып, индивидуаль үсеш траекторияләрен төзү;

Татарстан Республикасыннан читтә яшәүче сәләтле (талантлы) балаларның һәм яшьләрнең конкурс һәм проект чараларында катнашуын тәэмин итү;

конкурс чараларында җиңүчеләр өчен бүләкләү-стимуллаштыру механизмнарын булдыру;

сәләтле яшьләрнең яшәве, фәнни-белем бирү эшчәнлеге һәм һөнәри яктан үз мөмкинлекләрен тормышка ашыруы өчен матди ярдәм күрсәтү һәм шартлар тудыру чараларын эшләү.

7. Сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр белән эш алып бара торган учреждениеләр, шул исәптән махсуслаштырылган учреждениеләр челтәрен киңәйтү. Аларның эшчәнлеген кадрлар белән тәэмин итү:

мәктәпләр, югары һөнәр белеме бирү учреждениеләре, фәнни-тикшеренү институтлары, предприятиеләр, инновацион инфраструктура объектлары базасында һәм аерым структур бүлекчәләр рәвешендә дөньякүләм фәнни-техник үсешнең иң яңа тенденцияләрен чагылдыра торган өстенлекле юнәлешләр буенча сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр белән эшләү өчен учреждениеләр төзү (юнәлешен үзгәртү);

Казан (Идел буе) федераль университеты, А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ һәм Казан милли тикшеренү технология университеты базасында сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр өчен фәнни-белем бирү үзәкләрен төзү;

политехника музееи оештыру;

сәләтле (талантлы) балалар өчен интернат тибындагы мәктәп оештыру;

сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр өчен шәһәр читендә ел дәвамында эшли торган үзәк булдыру;

иң яхшы фәнни-педагогик кадрларны сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр белән эшкә тартуны стимуллаштыра торган механизмнар булдыру;

сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр белән эшли торган белгечләр әзерләү һәм яңадан әзерләү буенча база учреждениеләрен билгеләү;

сәләтлелек юнәлешләре буенча өстәмә белем бирү учреждениеләренең һәм яшүсмерләр клубларының сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр белән эшчәнлеген актуальләштерү;

мәктәп, студентлар каникуллары чорларында шәһәр читендәге савыктыру лагерьлары, белем бирү һәм ял итү үзәкләре базасында сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр өчен профильле сменалар оештыру.

8. Татарстан Республикасын инновацион үстерүгә йөз тоткан иҗтимагый формированиеләр, шул исәптән яшьләр берләшмәләре барлыкка килүне стимуллаштыра торган механизмнар булдыру:

иҗтимагый эшчәнлекне проектлау һәм социаль инновацияләр буенча сәләтле (талантлы) балаларга һәм яшьләргә белем бирү программаларын, шулай ук проект төркемнәрен формалаштыру механизмнарын эшләү һәм тормышка ашыру;

иҗтимагый формированиеләргә, шул исәптән перспективалы инновацион проектларны тормышка ашыручы яшьләр берләшмәләренә грант ярдәме күрсәтү механизмнарын үстерү;

республика өчен өстенлекле булган фәнни-җитештерү һәм социаль характердагы юнәлешләр буенча дәүләт заказларының һәм корпоратив заказларның яшьләр берләшмәләре өчен һәркем файдалана алырлык исемлеген булдыру һәм актуальләштерү.

9. Сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр белән эшнең перспективалы модельләрен эшләү һәм кертү, фәнни-тикшеренү эшен оештыру:

фәнни эшләнмәләргә һәм фәнни яктан тәэмин итүгә мохтаҗ булган перспективалы темалар һәм проектлар исемлеген формалаштыру;

сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр белән эш модельләрен әзерләүгә һәм кертүгә әйдәп баручы белем бирү һәм фән үзәкләрен җәлеп итү;

Концепцияне тормышка ашыруны мониторинглау һәм социологик тикшеренүләр оештыру, фәнни-гамәли семинарлар, экспертлар сессияләре, конференцияләр, лекцияләр, күргәзмәләр, фәнни форумнар һәм чаралар үткәрү;

фәнни, фәнни-популяр, уку-укыту-методик, белешмә, махсуслаштырылган әдәбият нәшер итү;

сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр белән эшне камилләштерү мәсьәләләре буенча норматив-хокукый документлар әзерләү.

10. Яшьләрнең перспективалы башлангычларын һәм проектларын мониторинглау һәм аларга максатчан ярдәм күрсәтү:

яшьләр башлангычларын, шулай ук яшьләр проектларын мониторинглау һәм аларны экспертизалау системасын стимуллаштыру механизмнарын булдыру;

аеруча перспективалы башлангычларны һәм проектларны сайлап алу һәм аларның мәгълүматлар базасын (фондын) формалаштыру максатыннан чыгып, яшьләрнең инновацион форумнарын, күргәзмәләрен, конкурсларын һәм конкурс мәйданчыкларын оештыру;

консультацияләр үткәрүне һәм башлангычларны һәм проектларны гамәлгә кертү һәм коммерция тәкъдиме дәрәҗәсенә кадәр җиткерүне тәэмин итә торган ресурслар үзәген үстерү;

перспективалы башлангычларны һәм проектларны тормышка ашыру өчен ресурслар, шулай ук потенциаль заказчылар һәм инвесторлар җәлеп итү механизмнарын эшләү;

перспективалы башлангычларны һәм проектларны хәл итү өчен командалар (проект төркемнәре) формалаштыру.

11. Эшчәнлекнең төрле юнәлешләре буенча кадрлар резервын формалаштыру:

кадрлар резервына кертү өчен сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр сайлап алу критерийларын билгеләү;

кадрлар резервы исәбе алып барыла торган юнәлешләрне һәм алар буенча җаваплылык үзәкләрен (министрлыкларны һәм ведомстволарны) билгеләү;

кадрлар резервын формалаштыру һәм исәпкә алу системасын алып бару;

эшчәнлекнең төрле өлкәләре буенча кадрлар резервы рейтингларын алып бару һәм мониторинглау методикаларын эшләү һәм кертү;

кадрлар резервын формалаштыруга һәм аннан файдалануга эш бирүчеләрне җәлеп итү механизмнарын булдыру;

Татарстан Республикасының әйдәп баручы белем бирү, фәнни-тикшеренү, сәнәгать предприятиеләре базасында стажировка һәм производство практикасы үткәрү механизмнарын кертү;

Татарстан Республикасында эшкә урнашканда кадрлар резервының төрле категорияләре статусын һәм аларны стимуллаштыру чараларын билгели торган норматив хокукый документлар эшләү.

12. Балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерүгә һәм тормышка ашыруга интеллектуаль, финанс һәм оештыру көчләрен туплауны, эшне ведомствоара координацияләүне, үзара хезмәттәшлекнең челтәр эчендәге механизмнарын тәэмин итү:

Концепцияне тормышка ашырганда ведомствоара эшчәнлекне координацияләү регламентларын эшләү;

Концепцияне тормышка ашыруга юнәлдерелгән комплекслы һәм максатчан программалар һәм проектлар эшләү;

Концепцияне тормышка ашырганда шәхси-дәүләт партнерлыгы механизмнарын үстерү;

вәкаләтле орган оештыру һәм Концепцияне тормышка ашыруга җәлеп ителгән субъектлар, партнерлар, операторлар белән үзара хезмәттәшлек итү системасын формалаштыру.

5. Концепцияне гамәлгә ашыруның күздә тотыла торган этаплары

Концепцияне өч этапта тормышка ашыру күздә тотыла, аны үткәрү вакытлары аның ресурслар белән тәэмин ителешенә бәйле булачак.

Аларның беренчесе – Концепцияне тормышка ашыру программасын кабул итүне һәм төп механизмнар булдыруны, икенчесе – Концепцияне тормышка ашыруда катнашучы субъектларның (партнерларның һәм операторларның) үзара хезмәттәшлек итү механизмнарын һәм төп юнәлешләрен тормышка ашыру технологияләрен эшләүне, өченчесе – балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм тормышка ашыруның бербөтен системасын төзүне күздә тота.

## 6. Концепцияне гамәлгә ашырудан көтелә торган нәтиҗәләр

Концепцияне гамәлгә ашырганда түбәндәге нәтиҗәләргә ирешү күздә тотыла:

1. Эшчәнлекнең төрле юнәлешләре буенча республика ярышларының, олимпиадаларының, конкурс чараларының барлык этапларында катнашучы балалар һәм яшьләр (һәм ачыклана торган сәләтле балалар һәм яшьләр) санын арттыру.

2. Бөтенроссия һәм халыкара конкурсларда призлы урыннар яулый торган һәм эшчәнлекнең төрле юнәлешләре буенча ярышларда, олимпиадаларда, конкурс чараларында катнашучы сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр санын арттыру.

3. Дөньякүләм үсешнең иң яңа идеяләрен, эшләнмәләрен һәм тенденцияләрен исәпкә ала торган республика конкурс чараларының еллык планын булдыру.

4. Россия Федерациясенең башка төбәкләреннән, ерак һәм якын чит илләрдән килгән һәм Татарстан Республикасында белем ала һәм эшкә урнаша торган студентлар өлешен арттыру.

5. Махсуслаштырылган республика порталында сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр турында даими тулыландырыла торган мәгълүматлар базасын булдыру.

6. Инновацион инфраструктура субъектлары территориясендә тормышка ашырыла торган проектларның гомуми санында сәләтле балалар һәм яшьләр катнашындагы инновацион проектлар санын һәм өлешен арттыру.

7. Республикадан сәләтле (талантлы) яшьләр китүне киметү.

8. Стандарт булмаган бурычларны иҗади хәл итәргә сәләтле командалар (проект төркемнәре) булдыру.

9. Махсуслаштырылган республика порталының мәгълүматлар базасыннан белгечләр һәм белгечләр командаларын сайлап алуга эш бирүчеләр гаризалары санын арттыру.

10. Дәүләт, муниципаль идарә өлкәсе һәм республика икътисадының төрле секторлары өчен кадрлар резервын булдыру.

Татарстан Республикасы Президентының
2012 елның «09» октябрендәге
ПУ-862 номерлы Указына
2 нче кушымта

# «Перспектива» Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм тормышка ашыру концепциясен гамәлгә ашыру буенча ведомствоара координация советы турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. «Перспектива» Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм тормышка ашыру концепциясен гамәлгә ашыру буенча ведомствоара координация советы (алга таба – Ведомствоара координация советы) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы коллегиаль орган булып тора.

Ведомствоара координация советы «Перспектива» Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм тормышка ашыру концепциясен гамәлгә ашыруны тәэмин итү, Татарстанның конкуренциягә сәләтле өстенлекләрен үстерү нигезе буларак балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм тормышка ашыру буенча республика системасын булдыру һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен үткәрү буенча бердәм мөнәсәбәтләр эшләү максатларында оештырыла.

2. Ведомствоара координация советы үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

## II. Ведомствоара координация советы бурычлары

3. Ведомствоара координация советының төп бурычлары:

Концепцияне гамәлгә ашыру һәм әлеге максатлар өчен кирәкле ресурслар җәлеп итү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм гамәлгә ашыру буенча төп юнәлешләрне эшләү һәм тиешле максатчан республика программаларын эшләүдә катнашу;

Концепцияне гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм учреждениеләрнең үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү;

сәләтле (талантлы) балалар һәм яшьләр белән эшләүне камилләштерү һәм Концепцияне тиешенчә үзгәртү инициативалары мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентына тәкъдимнәр эшләү;

Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм тормышка ашыру өлкәсендә кабул ителгән карарларны тормышка ашыру барышында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) эшчәнлеген координацияләү буенча тәкъдимнәр эшләү.

4. Ведомствоара координация советы үз бурычларын тормышка ашыру максатларында түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук җәмәгать берләшмәләреннән, предприятиеләрдән, учреждениеләрдән һәм оешмалардан законнар нигезендә мәгълүмат соратып алырга;

үз утырышларына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар җитәкчеләрен, вазыйфаи затларны чакырырга.

## III. Ведомствоара координация советы составы

5. Ведомствоара координация советы составы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

6. Ведомствоара координация советы составына Ведомствоара координация советы рәисе, рәис урынбасарлары, секретаре һәм әгъзалары керә.

7. Ведомствоара координация советының шәхси составы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгатьчелек, фәнни һәм бизнес-берләшмәләр вәкилләреннән формалаша.

## IV. Ведомствоара координация советының эш тәртибе

8. Ведомствоара координация советы эшен Ведомствоара координация советы рәисе (алга таба – Совет рәисе) оештыра.

9. Ведомствоара координация советы утырышлары расланган эш планнары нигезендә квартал саен үткәрелә. Кирәк булганда, Ведомствоара координация советының чираттан тыш утырышлары үткәрелергә мөмкин.

Ведомствоара координация советы утырышларын Совет рәисе яисә аның кушуы буенча урынбасарларның берсе алып бара.

10. Ведомствоара координация советы утырышларында көн тәртибен һәм мәсьәләләрне карау тәртибен Ведомствоара координация советы секретаре (алга таба – Совет секретаре) тәкъдиме буенча Совет рәисе билгели.

11. Ведомствоара координация советы әгъзалары үз эшчәнлеген җәмәгатьчелек башлангычларында гамәлгә ашыра һәм үз вәкаләтләрен башка затларга тапшырырга хокуклы түгел.

12. Ведомствоара координация советы утырышы, анда әгъзаларының яртысыннан күбрәге булганда, тулы хокуклы санала. Ведомствоара координация советы әгъзалары карарлар кабул иткәндә бертигез хокукларга ия.

Ведомствоара координация советы карарлары аның утырышында Ведомствоара координация советы әгъзаларының гомуми санынннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә. Тавышлар тигез булганда, Совет рәисе тавышы хәлиткеч санала. Ведомствоара координация советы карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аңа утырышта рәислек итүче һәм Совет секретаре кул куя.

13. Концепцияне гамәлгә ашыруга кагылышлы мәсьәләләрне әзерләү һәм карау өчен комиссияләр һәм эшче төркемнәр оештырылырга, кирәкле белгечләр җәлеп ителергә мөмкин.

14. Ведомствоара координация советы утырышларын оештыруны һәм аның карарлары проектларын әзерләүне тәэмин итүне Совет секретаре башкара.

## V. Совет рәисе вәкаләтләре

15. Совет рәисе:

Ведомствоара координация советы эшен оештыра;

Концепцияне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентына хәбәр итә;

Ведомствоара координация советы утырышларына материаллар әзерләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә;

Ведомствоара координация советы карарларының үтәлешен тикшереп торуны оештыра;

Концепцияне гамәлгә ашыруга кагылышлы республика максатчан программаларын эшләү һәм тормышка ашыру эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итә.

## VI. Совет сәркатибе вәкаләтләре

15. Совет сәркатибе Ведомствоара координация советының агымдагы эшчәнлеген тәэмин итә.

Совет сәркатибе:

Ведомствоара координация советы әгъзалары тәкъдимнәрен исәпкә алып, Ведомствоара координация советының эш планы проектларын әзерли, Ведомствоара координация советы утырышларының көн тәртибе буенча тәкъдимнәр формалаштыра;

Ведомствоара координация советы комиссияләрен һәм эшче төркемнәрен оештыру, аларның функцияләре һәм составы буенча Ведомствоара координация советына тәкъдимнәр кертә;

Ведомствоара координация советы комиссияләре һәм эшче төркемнәре эшләрен координацияли;

Ведомствоара координация советы карарлары проектларын әзерли;

кабул ителә торган карарларның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;

Ведомствоара координация советы утырышлары беркетмәләрен алып бара.

## VII. Ведомствоара координация советы эшчәнлеген тәэмин итү

16. Ведомствоара координация советы эшчәнлеген оештыру-техник һәм мәгълүмати тәэмин итү Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Президентының
2012 елның «09» октябрендәге
ПУ-862 номерлы Указына
3 нче кушымта

# «Перспектива» Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм тормышка ашыру концепциясен гамәлгә ашыру буенча ведомствоара координация советы составы

| | |
|---|---|
| Халиков Илдар Шәфкать улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры – совет рәисе |
| Моратов Марат Яшәр улы | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасары, совет рәисе урынбасары |
| Гафаров Шамил Хәмит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе – совет рәисе урынбасары |
| Кондратьев Андрей Станиславович | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министры урынбасары – совет сәркатибе |
| Агиев Шамил Рәхим улы | Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Әйделдинов Айнур Тәүфикъ улы | «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» дәүләт коммерциячел булмаган оешмасы директоры (килешү буенча) |
| Әминов Илшат Юныс улы | «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты (килешү буенча) |
| Белов Александр Николаевич | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты җитәкчесе |
| Бикчәнтәева Ләлә Дмитриевна | «Яшьләр казанышы» Казан үзәге» җәмәгать оешмасы башкарма директоры, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы (килешү буенча) |
| Борһанов Рафис Тимерхан улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министры |
| Гафуров Илшат Рәфкать улы | Казан (Идел буе) федераль университеты ректоры, Татарстан Республикасы югары һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләре ректорлары советы рәисе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Ефимов<br>Евгений Петрович | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр иҗтимагый палатасы рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Яшьләр сәясәте, сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру һәм Казан шәһәрендә 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге универсиаданы әзерләүгә ярдәм күрсәтү комиссиясе рәисе (килешү буенча) |
| Заһидуллина Миләүшә<br>Мөдәррис кызы | «Татарстан Республикасы яшьләрнең аграр берләшмәсе» төбәк җәмәгать оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Захарова<br>Светлана Михайловна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Лаврентьев<br>Александр Петрович | «Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм эшкуарлары ассоциациясе» төбәк эш бирүчеләр берләшмәсе президенты, «Казан вертолет заводы» ачык акционер җәмгыяте директорлар советы рәисе (килешү буенча) |
| Мазһаров Әхмәт<br>Мазһар улы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (килешү буенча) |
| Метшин Илсур<br>Рәис улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Муравьев<br>Ярослав Геннадиевич | «Татарстан Республикасы киләчәге факторы» яшьләр инициативаларына ярдәм күрсәтү буенча төбәк иҗтимагый фонды директоры, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының яшьләр сәясәте, физкультура һәм спорт мәсьәләләре буенча эш төркеме җитәкчесе (килешү буенча) |
| Процко<br>Екатерина Сергеевна | «Перспектива» талантлы яшьләр республика клубы җитәкчесе (килешү буенча) |
| Сибагатуллин Айрат<br>Миңнемулла улы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Синяшин<br>Олег Герольдович | Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге рәисе, Россия фәннәр академиясе Казан фәнни үзәгенең А.Е.Арбузов исемендәге Органик һәм физик химия институты директоры (килешү буенча) |
| Сохабеев<br>Валерий Михайлович | П.В.Дементьев исемендәге Казан авиация-техника көллияте директоры, Татарстан Республикасының урта махсус уку йортлары директорлары советы рәисе (килешү буенча) |
| Сөләйманов Тимур<br>Җәүдәт улы | «Татарстан Республикасы студентлар лигасы» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы президенты (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Терентьев Александр Михайлович | Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре идарәсе башлыгы |
| Туманин Виктор Евгеньевич | Татарстан Республикасы яшь галимнәренең һәм белгечләренең яшьләр иҗтимагый хәрәкәте башкарма комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Туманов Дмитрий Александрович | «Созвездие – Йолдызлык» иҗади сәләтле балаларга һәм яшьләргә ярдәм күрсәтү буенча республика үзәге» дәүләт учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Удачина Гүзәл Лүбис кызы | Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча) |
| Фәттахов Энгель Нәвап улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Черкесова Виктория Валерьевна | «Кадрлар резервы» республика проекты координаторы (килешү буенча) |
| Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улы | Татарстан Республикасы икътисад министры |
| Шәйхетдинов Роман Александрович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры |
| Шакиров Минсәгыйть Закир улы | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы рәисе (килешү буенча) |
| Шәфигуллин Айрат Радин улы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры |
| Юшко Сергей Владимирович | «Идея» инновация-җитештерү технопаркы» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Якупов Линар Габделнур улы | Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе. |

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1599. Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында

Терлекләрнең котыру авырулы булуы ачыклану һәм аның Татарстан Республикасы торак пунктларында таралу куркыны-

чы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының 3[1], 17 статьялары нигезендә **карар бирәм**:

1. Терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлек сәбәпле карантин кертергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Балтач районының Түбән Кенә авылы;

Биектау районының Татар Урматы авылы.

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Арча районының Кызыл Игенче авылындагы Дальняя урамы;

Арча районының Түбән Оры авылындагы Җиңү урамы;

Балтач районындагы Кара күл яны территориясе;

Казан шәһәренең Яңа Дәүләки урамы;

Казан шәһәренең Химическая урамындагы 7 номерлы йорт яны территориясе;

Саба районының Тимершык авылындагы Ленин урамы.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә карантин гамәле дәвам иткән вакытта түбәндәгеләр тыела:

йорт хайваннарын сату, аларны тиешле территориядән читкә чыгару;

котыру авырулы яисә авыру дигән шик тудырган хайваннарны ит өчен сую;

котыру авырулы терлекләрнең сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә пастеризацияләнмәгән сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә дезинфекцияләнмәгән йонын, тиресен әлеге территориядән чыгару.

3. Карантин, зарури чаралар күрү шарты үтәлгәндә, терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагы көненнән ике ай вакыт узгач бетерелергә тиеш, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә терлекләрнең котыру белән чирләвен бетерү буенча чаралар планнарын эшләргә һәм расларга, шулай ук аның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 09 октябрь
№ ПУ-863

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 1600. Татарстан Республикасы Алабуга шәһәренең аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлегә сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Алабуга шәһәренең Тынычлык проспектындагы 19 номерлы йортының йорт яны территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Алабуга шәһәренең аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга аның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2012 елның 24 июлендәге ПУ-616 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 09 октябрь
№ ПУ-864

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 1601. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм илебездә компрессор машиналары төзүне үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

«Казан компрессор машиналары төзү заводы» ачык акционер җәмгыятенең 17 номерлы запас частьләр цехы башлыгы — Денисов Вячеслав Александровичны

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 09 октябрь
№ ПУ-865

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1602. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте һәм Татарстан Республикасы халкын социаль яктан тәэмин итүне оештыруга зур өлеш кертүе өчен

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Мамадыш муниципаль районындагы социаль яклау идарәсе башлыгы — Муллахмәтова Миңнегөл Мирсәет кызын

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 09 октябрь
№ ПУ-866

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1603. «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының нефть һәм нефть химиясе сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе, актив иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге өчен

| | |
|---|---|
| хезмәт ветераны | Смагин Леонид Максимовичны |

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 09 октябрь
№ ПУ-867

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1604. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык намуслы хезмәтләре, целлюлоза-кәгазь производствосын үстерүгә зур өлеш кертүләре өчен «С.П. Титов исемендәге Чаллы катыргы-кәгазь комбинаты халык предприятиесе» эшчеләренең ябык акционер җәмгыяте катыргы фабрикасы хезмәткәрләре:

| | |
|---|---|
| кәгазь ваклаучы өлкән хезмәткәр | Антипин Андрей Кирилловичны |
| генераль директор | Бестолков Владимир Ивановичны |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 09 октябрь
№ ПУ-868

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1605. «Татарстан Республикасының Атказанган энергетигы» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, предприятие үсешенә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «С.П.Титов исемендәге Чаллы катыргы-кәгазь комбинаты халык предприятиесе» эшчеләренең ябык акционер җәмгыяте катыргы фабрикасы өлкән энергетигы | Рожнов Николай Михайловичка |

«Татарстан Республикасының Атказанган энергетигы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 09 октябрь
№ ПУ-869

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1606. «Татарстан Республикасының Атказанган азык-төлек сәнәгате хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Азык-төлек продукциясен җитештерү технологиясен камилләштерүдәге казанышы һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Татспиртпром» ачык акционер җәмгыяте филиалы – «Түбән Кама ликер-аракы заводы» ликер-аракы җитештерү цехы башлыгы | Шандырова Раиса Павловнага |

«Татарстан Республикасының Атказанган азык-төлек сәнәгате хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 10 октябрь
№ ПУ-870

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1607. Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм һәм аны үстерү өлкәсендә дәүләт җайга салуын тормышка ашыру мәсьәләләре

Кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм һәм аны үстерү өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы тормышка ашыра торган кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм һәм аны үстерү өлкәсендә дәүләт җайга салуы функцияләрен Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына тапшырырга.

2. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, төзелгән килешүләр һәм шартнамәләрдән, шулай ук эшчәнлекнең кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм һәм аны үстерү өлкәсендә дәүләт җайга салуы функцияләрен законнар нигезендә тормышка ашыру белән бәйле башка мәсьәләләрдән килеп чыгучы йөкләмәләр өлешендә, Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының хокукый дәвамчысы булып тора, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы турында» 2011 елның 1 июнендәге ПУ-298 номерлы Указына, 1 пунктның икенче абзацыннан «һәм Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү мәсьәләләре буенча вәкаләтләр» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» 2008 елның 23 июнендәге ПУ-300 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 5 мартындагы ПУ-124 номерлы, 2009 елның 13 июнендәге ПУ-328 номерлы, 2009 елның 13 ноябрендәге ПУ-606 номерлы, 2009 елның 17 ноябрендәге ПУ-611 номерлы, 2010 елның 22 мартындагы ПУ-158 номерлы, 2010 елның 21 апрелендәге ПУ-253 номерлы, 2010 елның 10 июнендәге ПУ-378 номерлы, 2010 елның 3 августындагы ПУ-512 номерлы, 2010 елның 11 октябрендәге ПУ-681 номерлы, 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-712 номерлы, 2010 елның 23 декабрендәге ПУ-855 номерлы, 2011 елның 15 гыйнварындагы ПУ-7 номерлы, 2011 елның 31 гыйнварындагы ПУ-33 номерлы, 2011 елның 3 февралендәге ПУ-42 номерлы, 2011 елның 23 мартындагы ПУ-143 номерлы, 2011 елның 11 апрелендәге ПУ-194 номерлы, 2011 елның 29 июлендәге ПУ-459 номерлы, 2011 елның 19 августындагы ПУ-508 номерлы, 2011 елның 5 сентябрендәге ПУ-543 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-620 номерлы, 2011 елның 13 октябрендәге ПУ-646 номерлы, 2011 елның 25 октябрендәге ПУ-676 номерлы, 2011 елның 25 октябрендәге ПУ-677 номерлы, 2011 елның 25 ноябрендәге ПУ-748 номерлы, 2011 елның 30 ноябрендәге

ПУ-774 номерлы, 2012 елның 18 гыйнварындагы ПУ-23, 2012 елның 10 мартындагы ПУ-190 номерлы һәм 2012 елның 13 апрелендәге ПУ-257 номерлы, 2012 елның 11 июнендәге ПУ-460 номерлы, 2012 елның 23 июнендәге ПУ-495 номерлы, 2012 елның 27 июлендәге ПУ-622 номерлы, 2012 елның 30 июлендәге ПУ-624 номерлы, 2012 елның 13 августындагы ПУ-649 номерлы, 2012 елның 20 августындагы ПУ-680 номерлы, 2012 елның 23 августындагы ПУ-689 номерлы һәм 2012 елның 29 сентябрендәге ПУ-823 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 пунктта «135» санын «155» санына алмаштырырга;

28 пунктта «46» санын «26» санына алмаштырырга.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү мәсьәләләре буенча вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына тапшыруны тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының аерым вәкаләтләрен тапшыру белән бәйле чаралар комплексын законнарда билгеләнгән тәртиптә тормышка ашыруны тәэмин итәргә;

үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 11 октябрь
№ ПУ-871

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1608. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләрен резервка калдыру турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт резерв җир фонды эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләрен резервка калдыру турында» 2004 елның 22 гыйнварындагы ПУ-26 номерлы Указына редакциядә бәян итеп, түбәндәге үзгәреш кертергә:

«4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт резерв җир фонды булдыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә. Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе Нуретдинов Айрат Рәфкать улын Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт резерв җир фондының Попечительләр советы рәисе итеп билгеләп куярга.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 11 октябрь
№ ПУ-872

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1609. Татарстан Республикасында алкогольле һәм спиртлы продукция әйләнеше өлкәсендәге вәзгыятьне контрольдә тоту советы составына үзгәрешләр кертү хакында

Аерым затларның башка эшкә күчүләре белән бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында алкогольле һәм спиртлы продукция әйләнеше өлкәсендәге вәзгыятьне контрольдә тоту советын төзү турында» 2010 елның 3 февралендәге ПУ-41 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 3 июнендәге ПУ-363 номерлы, 2010 елның 30 декабрендәге ПУ-889 номерлы, 2011 елның 23 мартындагы ПУ-144 номерлы, 2011 елның 3 ноябрендәге ПУ-699 номерлы һәм 2012 елның 5 июлендәге ПУ-539 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасында алкогольле һәм спиртлы продукция әйләнеше өлкәсендәге вәзгыятьне контрольдә тоту советы (алга таба – Совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Совет составыннан А.Х. Гыйльметдиновны, М.Я. Моратовны чыгарырга;

б) Совет составына кертергә:

Миңнәхмәтов Ирек Җәүдәт улын – «ТАТМЕДИА» ачык акционер җәмгыяте генераль директорын (килешү буенча);

Фәттахов Энгель Нәвап улын – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрын.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 13 октябрь
№ ПУ-874

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1610. Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында

Терлекләрнең котыру авырулы булуы ачыклану һәм аның Татарстан Республикасы торак пунктларында таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлек сәбәпле карантин кертергә:

Кайбыч районының Кичкеево авылы;

Саба районының Пукәл авылы.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә карантин гамәле дәвам иткән вакытта түбәндәгеләр тыела:

йорт хайваннарын сату, аларны тиешле территориядән читкә чыгару;

котыру авырулы яисә авыру дигән шик тудырган хайваннарны ит өчен сую;

котыру авырулы терлекләрнең сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә пастеризацияләнмәгән сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә дезинфекцияләнмәгән йонын, тиресен әлеге территориядән чыгару.

3. Карантин, зарури чаралар күрү шарты үтәлгәндә, терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагы көненнән ике ай вакыт узгач бетерелергә тиеш, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә терлекләрнең котыру белән чирләвен бетерү буенча чаралар планнарын эшләргә һәм расларга, шулай ук аның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 13 октябрь
№ ПУ-875

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1611. «Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм мәдәниятне үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Әлмәт муниципаль районының «1 номерлы балалар сәнгать мәктәбе» балаларга өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе укытучысы | Гарифуллина Илмира Шамил кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 16 октябрь
№ ПУ-876

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1612. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте һәм Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Кулон агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте финанс директоры | Фәхретдинов Альберт Шамил улын |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 17 октябрь
№ ПУ-877

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1613. Татарстан Республикасының Азнакай районы Сарлы авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында

Терлекләрнең котыру авырулы булуы ачыклану һәм аның Татарстан Республикасы торак пунктларында таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары нигезендә **карар бирәм**:

1. Терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертергә:

а) Татарстан Республикасының Азнакай районы Сарлы авылы территориясендә;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Азнакай районы Банки-Сукаеш авылы янындагы «Азнакайнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсенең СКН 4298 номерлы нефть скважинасы яны территориясе;

Алексеевск районының Зур Тигәнәле авылы янындагы «Алан» фермер хуҗалыгы.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә карантин гамәле дәвам иткән вакытта түбәндәгеләр тыела:

йорт хайваннарын сату, аларны әлеге территориядән читкә чыгару;

котыру авырулы яисә авыру дигән шик тудыра торган хайваннарны ит өчен сую;

котыру авырулы терлекләрнең сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә пастеризацияләнмәгән сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә дезинфекцияләнмәгән йонын, тиресен әлеге территориядән чыгару.

3. Карантин, зарури чаралар күрү шарты үтәлгәндә, терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагы көненнән ике ай вакыт узгач бетерелергә тиеш, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә терлекләрнең котыру белән чирләвен бетерү буенча чаралар планнарын эшләргә һәм расларга, шулай ук аларның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 18 октябрь
№ ПУ-878

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 1614. Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләү турында

Күп бала табып, аларны намус белән тәрбияләгән ишле бала аналарын Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләргә:

Актаныш муниципаль районы буенча

| | |
|---|---|
| Иске Богады авылыннан алты бала анасы | Гиндуллина Фәридә Асаф кызын |

Аксубай муниципаль районы буенча

| | |
|---|---|
| Иске Үзи авылыннан биш бала анасы | Захарова Людмила Александровнаны |
| Мюд поселогыннан сигез бала анасы | Лимонова Валентина Евграфовнаны |
| Савгач авылыннан биш бала анасы | Семенова Нина Викторовнаны |
| Иске Ибрай авылыннан биш бала анасы | Таһирова Рәисә Әсәдулла кызын |

Теләче муниципаль районы буенча

| | |
|---|---|
| Алан авылыннан биш бала анасы | Шәрәфиева Гузәлия Мингәли кызын |

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 18 октябрь
№ ПУ-879

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 1615. Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты турында

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты структурасын һәм эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты структурасында составында Дини берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек идарәсе, Милли сәясәтне гамәлгә ашыру идарәсе, Граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлек идарәсе булган Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты төзергә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаментының Дини берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек идарәсе үз эченә дәүләт-конфессиональ мөнәсәбәтләр бүлеген һәм мәгариф программалары һәм проектлары бүлеген ала;

Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаментының Граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлек идарәсе үз эченә иҗтимагый-сәяси һәм коммерциячел булмаган оешмалар белән үзара хезмәттәшлек бүлеген һәм гамәли тикшеренүләр һәм проектлар бүлеген ала.

3. Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре идарәсен, Татарстан Республикасы Президентының Дини берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек идарәсен кыскартырга, аларның 18 берәмлек штат санын Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаментына тапшырырга.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестры турында» 2006 елның 18 гыйнварындагы ПУ-9 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 12 мартындагы ПУ-121 номерлы, 2010 елның 1 апрелендәге ПУ-183 номерлы, 2010 елның 10 июнендәге ПУ-378 номерлы, 2010 елның 30 июнендәге ПУ-416 номерлы, 2010 елның 3 августындагы ПУ-512 номерлы, 2010 елның 2 сентябрендәге ПУ-585 номерлы, 2011 елның 31 гыйнварындагы ПУ-34 номерлы, 2011 елның 20 июлендәге ПУ-360 номерлы, 2011 елның 5

октябрендәге ПУ-620 номерлы, 2011 елның 13 октябрендәге ПУ-646 номерлы, 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы, 2012 елның 20 февралендәге ПУ-126 номерлы, 2012 елның 24 маендагы ПУ-375 номерлы, 2012 елның 13 августындагы ПУ-649 номерлы һәм 2012 елның 20 августындагы ПУ-681 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестрының 1 бүлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1 бүлектә:

« Татарстан Республикасы Президенты
идарәсе башлыгы 01-1-1-04»

позициясеннән соң түбәндәге эчтәлекле позиция өстәргә:

« Татарстан Республикасы Президенты
Департаменты җитәкчесе 01-1-1-04[1]»;

« Татарстан Республикасы Президенты
Эшләр идарәчесе урынбасары 01-1-2-10»

позициясеннән соң түбәндәге эчтәлекле позицияләр өстәргә:

« Татарстан Республикасы Президенты
Департаменты җитәкчесе урынбасары 01-1-2-10[1]

Татарстан Республикасы Президенты
Департаменты җитәкчесе урынбасары –
Татарстан Республикасы Президенты
Департаменты идарәсе башлыгы 01-1-2-10[2]

Татарстан Республикасы Президенты
Департаменты идарәсе башлыгы 01-1-2-10[3]»;

« Татарстан Республикасы Президенты
идарәсе башлыгы урынбасары 01-1-2-12»

позициясеннән соң түбәндәге эчтәлекле позиция өстәргә:

« Татарстан Республикасы Президенты
Департаменты идарәсе башлыгы урынбасары 01-1-2-12[1]

Татарстан Республикасы Президенты
Департаменты идарәсе башлыгы урынбасары –
Татарстан Республикасы Президенты

Департаменты идарәсе бүлек мөдире 01-1-2-12[2]»;

б) 3 бүлектә:

« Татарстан Республикасы Президенты идарәсе, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Департамент, Татарстан Республикасы Президенты Департаменты составындагы бүлек мөдире 01-3-2-22»

позициясен түбәндәге эчтәлекле позициягә алмаштырырга:

« Татарстан Республикасы Президенты идарәсе, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Департамент, Татарстан Республикасы Президенты Департаменты, Татарстан Республикасы Президенты Департаменты идарәсе составындагы бүлек мөдире 01-3-2-22».

5. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты турында нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 20 мартындагы ПУ-114 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 12 мартындагы ПУ-121 номерлы, 2010 елның 1 апрелендәге ПУ-183 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-622 номерлы, 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы һәм 2012 елның 13 августындагы ПУ-649 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты Аппараты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 8 пунктның беренче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмләләр өстәргә: «Татарстан Республикасы Президенты карары нигезендә Татарстан Республикасы Президенты Департаменты составында департаментның структур бүлекчәсе булып торган идарәләр (алга таба – Департамент идарәсе) төзелергә мөмкин. Департамент идарәсендә бүлекләр дә төзелергә мөмкин.»;

б) 12 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәчесе урынбасары» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы Президенты Департаменты җитәкчесе урынбасары, Татарстан Республикасы Президенты Департаменты җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президенты Департаменты идарәсе башлыгы, Татарстан

Республикасы Президенты Департаменты идарәләре башлыклары,» сүзләрен өстәргә.

6. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты турында» 2006 елның 5 апрелендәге ПУ-134 номерлы Указының (Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 16 июнендәге ПУ-223 номерлы, 2006 елның 10 ноябрендәге ПУ-466 номерлы, 2007 елның 21 июнендәге ПУ-323 номерлы, 2008 елның 29 августындагы ПУ-425 номерлы, 2010 елның 12 мартындагы ПУ-121 номерлы, 2010 елның 1 апрелендәге ПУ-183 номерлы, 2010 елның 12 июлендәге ПУ-445 номерлы, 2010 елның 25 декабрендәге ПУ-863 номерлы, 2011 елның 15 гыйнварындагы ПУ-7 номерлы номерлы, 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы, 2012 елның 30 июлендәге ПУ-624 номерлы һәм 2012 елның 13 августындагы ПУ-649 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 пунктына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«составына:

Дини берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек идарәсе, Милли сәясәтне гамәлгә ашыру идарәсе, Граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлек идарәсе кергән Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты;»;

б) алтынчы абзацны төшереп калдырырга;

в) җиденче – егерме өченче абзацларны тиешенчә алтынчы – егерме икенче абзацлар дип санарга.

7. Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-620 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы, 2012 елның 18 гыйнварындагы ПУ-24 номерлы, 2012 елның 10 мартындагы ПУ-188 номерлы, 2012 елның 11 июлендәге ПУ-559 номерлы, 2012 елның 16 июлендәге ПУ-587 номерлы, 2012 елның 30 июлендәге ПУ-624 номерлы, 2012 елның 13 августындагы ПУ-649 номерлы һәм 2012 елның 20 августындагы ПУ-680 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты Аппараты структурасына һәм хезмәткәрләренең чик санына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а)

**«Татарстан Республикасы Президентының**
**Эчке сәясәт мәсьәләләре идарәсе**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 28. | Идарә башлыгы | 1 | |

**Иҗтимагый-сәяси берләшмәләр белән**
**хезмәттәшлек итү бүлеге**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 29. | Бүлек мөдире | 1 | |
| 30. | Баш киңәшче | 2 | |

**Этник сәясәт бүлеге**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 31. | Бүлек мөдире | 1 | |
| 32. | Баш киңәшче | 2 | |

**Мәгълүмат-аналитика секторы**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 33. | Сектор мөдире | 1 | |
| 34. | Әйдәүче белгеч | 2 | |
| | | | |
| | **Идарә буенча барлыгы** | 9 | |

**Татарстан Республикасы Президентының**
**Дини берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек идарәсе**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 35. | Идарә башлыгы | 1 | |
| 36. | Идарә башлыгы урынбасары | 1 | |

**Мәгълүмат-аналитика бүлеге**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 37. | Бүлек мөдире | 1 | |
| 38. | Баш киңәшче | 3 | |

**Дәүләт-конфессиональ мөнәсәбәтләр бүлеге**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 39. | Бүлек мөдире | 1 | |
| 40. | Баш киңәшче | 2 | |
| | | | |
| | **Идарә буенча барлыгы** | **9** | |

»;

сүзләрен һәм позицияләрен түбәндәге эчтәлекле сүзләргә һәм позицияләргә алмаштырырга:

**«Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 28. | Департамент җитәкчесе | 1 | |
| 29. | Департамент җитәкчесе урынбасары | 1 | |

**Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаментының Дини берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек идарәсе**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 30. | Идарә башлыгы | 1 | |

**Дәүләт-конфессиональ мөнәсәбәтләр бүлеге**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 31. | Бүлек мөдире | 1 | |
| 32. | Баш киңәшче | 8 | |

**Мәгариф программалары һәм проектлары бүлеге**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 33. | Идарә башлыгы урынбасары –<br>бүлек мөдире | 1 | |
| 34. | Баш киңәшче | 4 | |

**Татарстан Республикасы Президентының
Эчке сәясәт мәсьәләләре департаментының
Милли сәясәтне гамәлгә ашыру идарәсе**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 35. | Идарә башлыгы | 1 | |
| 36. | Идарә башлыгы урынбасары | 1 | |
| 37. | Баш киңәшче | 7 | |

**Татарстан Республикасы Президентының
Эчке сәясәт мәсьәләләре департаментының Граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлек идарәсе**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 38. | Департамент җитәкчесе урынбасары – идарә башлыгы | 1 | |

**Иҗтимагый-сәяси һәм коммерциячел булмаган оешмалар
белән үзара хезмәттәшлек бүлеге**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 39. | Идарә башлыгы урынбасары – бүлек мөдире | 1 | |
| 40. | Баш киңәшче | 5 | |

**Гамәли тикшеренүләр һәм проектлар бүлеге**

| | | | |
|---|---|---|---|
| $40^1$. | Бүлек мөдире | 1 | |
| $40^2$. | Баш киңәшче | 6 | |

»;

б)

«

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ БУЕНЧА БАРЛЫГЫ** | **203** | |

»

позициясен түбәндәге эчтәлекле позициягә алмаштырырга:

«

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ БУЕНЧА БАРЛЫГЫ** | **225** | |

».

8. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгән затларның вазыйфаи окладлары турында» 2006 елның 5 апрелендәге ПУ-142 номерлы Указына кушымтага (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 13 мартындагы ПУ-128 номерлы, 2010 елның 19 апрелендәге ПУ-238 номерлы, 2010 елның 21 июнендәге ПУ-394 номерлы, 2010 елның 8 сентябрендәге ПУ-596 номерлы, 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы һәм 2012 елның 13 августындагы ПУ-649 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән), Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2007 елның 3 декабрендәге ПУ-647 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2008 елның 3 октябрендәге ПУ-490 номерлы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2012 елның 13 августындагы ПУ-646 номерлы указларының нигезләмәләрен исәпкә алып, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а)

«

| | | |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Президенты идарәсе башлыгы | 01-1-1-04 | 7640-8125 |

»

позициясеннән соң түбәндәге эчтәлекле позиция өстәргә:

«

| | | |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Президенты Департаменты җитәкчесе | 01-1-1-04[1] | 8613 |

»;

б)

«

| | | |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәчесе урынбасары | 01-1-2-10 | 7800 |

»

позициясеннән соң түбәндәге эчтәлекле позицияләр өстәргә:

«

| | | |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Президенты Департаменты җитәкчесе урынбасары | 01-1-2-10[1] | 8099 |

| | | |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Президенты Департаменты җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президенты Департаменты идарәсе башлыгы | 01-1-2-10[2] | 8099 |
| Татарстан Республикасы Президенты Департаменты идарәсе башлыгы | 01-1-2-10[3] | 8099 |

»;

в)

«

| | | |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Президенты идарәсе башлыгы урынбасары | 01-1-2-12 | 7355 |

»

позициясеннән соң түбәндәге эчтәлекле позицияләр өстәргә:

«

| | | |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Президенты Департаменты идарәсе башлыгы урынбасары | 01-1-2-12[1] | 7797 |
| Татарстан Республикасы Президенты Департаменты идарәсе башлыгы урынбасары – Татарстан Республикасы Президенты Департаменты идарәсе бүлек мөдире | 01-1-2-12[2] | 7797 |

»;

г)

«

| | | |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Президенты идарәсе, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Департамент, Татарстан Республикасы Президенты Департаменты составындагы бүлек мөдире | 01-3-2-22 | 7120 |

»

позициясен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| | | |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Президенты идарәсе, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Департамент, Татарстан Республикасы Президенты Департаменты, Татарстан Республикасы Президенты Департаменты идарәсе составындагы бүлек мөдире | 01-3-2-22 | 7548 |

».

9. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» 2008 елның 23 июнендәге ПУ-300 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 5 мартындагы ПУ-124 номерлы, 2009 елның 13 июнендәге ПУ-328 номерлы, 2009 елның 13 ноябрендәге ПУ-606 номерлы, 2009 елның 17 ноябрендәге ПУ-611 номерлы, 2010 елның 22 мартындагы ПУ-158 номерлы, 2010 елның 21 апрелендәге ПУ-253 номерлы, 2010 елның 10 июнендәге ПУ-378 номерлы, 2010 елның 3 августындагы ПУ-512 номерлы, 2010 елның 11 октябрендәге ПУ-681 номерлы, 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-712 номерлы, 2010 елның 23 декабрендәге ПУ-855 номерлы, 2011 елның 15 гыйнварындагы ПУ-7 номерлы, 2011 елның 31 гыйнварындагы ПУ-33 номерлы, 2011 елның 3 февралендәге ПУ-42 номерлы, 2011 елның 23 мартындагы ПУ-143 номерлы, 2011 елның 11 апрелендәге ПУ-194 номерлы, 2011 елның 29 июлендәге ПУ-459 номерлы, 2011 елның 19 августындагы ПУ-508 номерлы, 2011 елның 5 сентябрендәге ПУ-543 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-620 номерлы, 2011 елның 13 октябрендәге ПУ-646 номерлы, 2011 елның 25 октябрендәге ПУ-676 номерлы, 2011 елның 25 октябрендәге ПУ-677 номерлы, 2011 елның 25 ноябрендәге ПУ-748 номерлы, 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы, 2012 елның 18 гыйнварындагы ПУ-23 номерлы, 2012 елның 10 мартындагы ПУ-190 номерлы, 2012 елның 13 апрелендәге ПУ-257 номерлы, 2012 елның 11 июнендәге ПУ-460 номерлы, 2012 елның 23 июнендәге ПУ-495 номерлы, 2012 елның 27 июлендәге ПУ-622 номерлы, 2012 елның 30 июлендәге ПУ-624 номерлы, 2012 елның 13 августындагы ПУ-649 номерлы, 2012 елның 20 августындагы ПУ-680 номерлы һәм 2012 елның 23 августындагы ПУ-689 номерлы указлары нигезендә кертелгән

үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтага, 1 пункттагы «193» санын «215» санына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

10. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенә законнар нигезендә билгеләнгән срокларда һәм тәртиптә әлеге Указны гамәлгә ашыру буенча оештыру-штат чаралары уздырырга.

11. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты хезмәткәрләре, алар ризалык биргәндә, оештыру-штат чаралары тәмамланганчы, элек биләгән вазыйфалары буенча хезмәт вазыйфаларын башкаруны дәвам итәләр, дип билгеләргә.

12. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе билгеләнгән тәртиптә бер ай вакыт эчендә Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты нигезләмәсен раслау өчен тәкъдим итәргә.

13. Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсенә өч ай эчендә Татарстан Республикасы Президентының һәм Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең актларын әлеге Указга туры китерү турында тәкъдимнәр кертергә.

14. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре идарәсе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 15 маендагы ПУ-175 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 12 июлендәге ПУ-445 номерлы Указына кушымтаның 6 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Дини берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек идарәсе турында» 2010 елның 25 декабрендәге ПУ-863 номерлы Указының 1 һәм 2 пунктлары;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Дини берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек идарәсе турында нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 11 февралендәге ПУ-54 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-622 номерлы Указына кушымтаның 5 пункты.

15. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 19 октябрь
№ ПУ-880

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1616. Татарстан Республикасы Президентының «Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгын бетерү турында» Указының үз көчен югалтуын тану хакында

Татарстан Республикасында матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә дәүләт идарәсен камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Конституциясенең 94 статьясы, «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгын бетерү турында» 2012 елның 13 августындагы ПУ-648 номерлы Указының үз көчен югалтуын танырга.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы турында» 2009 елның 15 маендагы ПУ-278 номерлы Указы Татарстан Республикасы Президентының «Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгын бетерү турында» 2012 елның 13 августындагы ПУ-648 номерлы Указы чыкканга кадәр гамәлдә булган редакциядә гамәлдә була, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгын бетерү процедурасын туктату чараларын күрергә;

үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы эшчәнлеген тәэмин итү буенча башка карарлар кабул итәргә;

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы хезмәткәрләре санын оптимальләштерү чараларын уздыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 19 октябрь
№ ПУ-881

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1617. А.М. Терентьевны Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе итеп билгеләп кую турында

Терентьев Александр Михайловичны, элек биләгән вазыйфасыннан азат итеп, Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе итеп билгеләп куярга.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 19 октябрь
№ ПУ-882

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1618. 2013 елны Татарстан Республикасында Экологик культура һәм әйләнә-тирә мохитне саклау елы дип игълан итү турында

Әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләренә җәмгыятьнең игътибарын җәлеп итү, экологик культура формалаштыру һәм аны үстерү максатларында **карар бирәм**:

1. 2013 елны Татарстан Республикасында Экологик культура һәм әйләнә-тирә мохитне  саклау елы дип игълан итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бер ай вакыт эчендә 2013 елда Татарстан Республикасында Экологик культура һәм әйләнә-тирә мохитне саклау елын уздыру буенча төп чаралар планын, аларны уздыру вакытын, җаваплы башкаручыларын, финанслау күләмен һәм чыганакларын күрсәтеп, әзерләргә һәм расларга, шулай ук аны гамәлгә ашыруга контрольне тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, җәмәгать берләшмәләренә һәм оешмаларга Татарстан Республикасында Экологик культура һәм әйләнә-тирә мохитне саклау елын әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

4. «ТАТМЕДИА» ачык акционер җәмгыятенә, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционер җәмгыятенә, республика һәм җирле массакүләм мәгълүмат чараларына Татарстан Республикасында Экологик культура һәм әйләнә-тирә мохитне саклау елын уздыруны киң яктыртуны тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 октябрь
№ ПУ-883

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1619. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә классы чиннар бирү турында

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә түбәндәге классы чиннарны бирергә:

Татарстан Республикасы
Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы буенча

**Татарстан Республикасының**
**3 классы хакыйкый дәүләт киңәшчесе**

министр урынбасары — Баһманов Хәмзә Әзәл улына

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы буенча

**Татарстан Республикасының**
**1 класслы хакыйкый дәүләт киңәшчесе**

министр урынбасары | Рагозина Надежда Владимировнага

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 октябрь
№ ПУ-884

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1620. Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлегә сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Сарман районының Карашай-Саклау авылы;

Балтач районының Чапшар авылы;

Балтач районының Борбаш авылы;

Балтач районының Сасна Пүчинкәсе авылы;

Түбән Кама районының Шәңгәлче авылы;

б) Татарстан Республикасы Балтач районы Урта Көшкәт авылының Депутат урамы территориясендә.

2. Үз көчен югалткан, дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2012 елның 3 августындагы ПУ-638 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасы Балтач районының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2012 елның 10 августындагы ПУ-644 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасы Балтач районының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2012 елның 10 августындагы ПУ-644 номерлы Указына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 1 сентябрендәге ПУ-733 номерлы Указы.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 октябрь
№ ПУ-885

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1621. «Татарстан Республикасының Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Нәтиҗәле хезмәте һәм халык сәламәтлеген саклаудагы казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе дару чаралары һәм медицина билгеләнешендәге эшләнмәләре әйләнешенә контроль бүлеге башлыгы | Хәсәнова Зәйнәп Зиннәтулла кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 октябрь
№ ПУ-886

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 1622. И.З. Миңнәхмәтовны Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе итеп билгеләп кую турында

Миңнәхмәтов Ирек Җәүдәт улын Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе итеп билгеләп куярга.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 октябрь
№ ПУ-887

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 1623. «Татарстан Республикасының Атказанган машина төзүчесе» дигән мактаулы исем бирү турында

Стандартлаштыру, метрология һәм сынаулар уздыру өлкәсендәге казанышлары, күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Татарстан Республикасында стандартлаштыру, метрология һәм сынаулар уздыру дәүләт төбәк үзәге» федераль бюджет учреждениесенең стандартлаштыру бүлеге башлыгы | Мискичева Маргарита Викторовнага |

«Татарстан Республикасының Атказанган машина төзүчесе» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 октябрь
№ ПУ-888

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1624. «Татарстан Республикасының Атказанган химигы» дигән мактаулы исем бирү турында

Химия өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Татарстан Республикасында стандартлаштыру, метрология һәм сынаулар уздыру буенча дәүләт төбәк үзәге» федераль бюджет учреждениесенең азык-төлек продукциясе һәм азык-төлек чималын тикшерү лабораториясе әйдәүче инженеры | Кашапова Гөлсем Марат кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган химигы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 октябрь
№ ПУ-889

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1625. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, финанс-икътисад эшчәнлегендәге казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Казначылык департаменты директоры | Фәйзрахманов Марат Җәүдәт улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 октябрь
№ ПУ-890

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1626. «Татарстан Республикасының Атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтүне оештырудагы казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге баш белгече | Кадыйрова Рима Назыйф кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 октябрь
№ ПУ-891

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1627. «Татарстан Республикасының Атказанган архитекторы» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, архитектура һәйкәлләрен реставрацияләү һәм торгызу эшләрен башкарудагы казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| «РесСтро» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры, Казан шәһәре | Хәйбуллин Равил Гариф улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган архитекторы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 октябрь
№ ПУ-892

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1628. «Татарстан Республикасының Атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Оператив-хезмәт эшчәнлегендә югары нәтиҗәләргә ирешүләре һәм эчке эшләр органнарында күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен «Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының ведомстводан тыш сак идарәсе» федераль дәүләт казна учреждениесенең Югары вазыйфаи затларның куркынычсызлыгын тәэмин итү үзәге хезмәткәрләре:

| | |
|---|---|
| оператив чара күрү бүлеге башлыгы урынбасары – 1 нче бүлекчә башлыгы, полиция подполковнигы | Гаврилов Александр Павловичка |
| махсус әзерлек бүлеге баш белгече, полиция подполковнигы | Суворов Евгений Александровичка |

«Татарстан Республикасының Атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 октябрь
№ ПУ-893

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1629. «Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирү турында

Татарстан Республикасында күчемсез милек хокукларын дәүләт теркәве системасын үстерүдәге казанышлары өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре:

| | |
|---|---|
| күчемсез милек объектларына арест салуларны дәүләт теркәве һәм аларга хокукларны теркәү турындагы мәгълүмат бирү бүлеге башлыгы | Гончарова Галина Юрьевнага |
| юридик затлар хокукларын һәм өлешле катнашу шартнамәләрен дәүләт теркәве бүлеге башлыгы | Трифонова Ирина Александровнага |

«Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 октябрь
№ ПУ-894

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1630. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Халык сәламәтлеген саклау эшендәге казанышлары һәм югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгы «Казан дәүләт медицина университеты» югары һөнәри белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең неврология һәм реабилитация кафедрасы мөдире | Богданов Әнвәр Ибраһим улын |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 октябрь
№ ПУ-895

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1631. «Татарстан Республикасының Атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Элемтә чараларының югары сыйфатлы һәм өзлексез эшләвен тәэмин итүдә казанышлары өчен

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Эшләр идарәсенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшчәнлеген мәгълүмати-технологик тәэмин итү бүлеге мөдире — Хәсәнов Зөфәр Хөсәен улына

«Татарстан Республикасының Атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 октябрь
№ ПУ-896

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1632. «Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирү турында

Татарстан Республикасының җирле үзидарә өлкәсендәге гамәлдәге законнары һәм нормативлары таләпләрен үтәүне тәэмин итүдәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен

Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советының юридик бүлеге башлыгы — Корманова Луиза Мансур кызына

«Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 октябрь
№ ПУ-897

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1633. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Нәтиҗәле хезмәте, финанс-икътисад эшчәнлегендәге казанышлары һәм Татарстан Республикасының нефть сәнәгатен үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ачык акционер җәмгыяте финанс идарәсенең валюта бүлеге башлыгы | Алленов Владимир Алексеевичка |

«Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 октябрь
№ ПУ-898

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1634. «Татарстан Республикасының Атказанган нефтьчесе» дигән мактаулы исем бирү турында

Нәтиҗәле хезмәте һәм Татарстан Республикасының нефть сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Татнефть-РемСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директорының беренче урынбасары – җәмгыятьнең баш инженеры | Стерлядев Юрий Рафаиловичка |

«Татарстан Республикасының Атказанган нефтьчесе» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 октябрь
№ ПУ-899

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1635. «Татарстан Республикасының Атказанган торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалау программасын гамәлгә ашыруга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Торак-коммуналь хуҗалыгы предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры, Казан шәһәре | Антонов Эдуард Владимировичка |

«Татарстан Республикасының Атказанган торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 октябрь
№ ПУ-902

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1636. Татарстан Республикасының Спас районының кайбер торак пунктларында һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында

Терлекләрнең котыру авырулы булуы ачыклану һәм аның Татарстан Республикасы торак пунктларында таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары нигезендә **карар бирәм**:

1. Терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертергә:

а) Татарстан Республикасы Спас районының түбәндәге торак пунктларында:

Никольский авылы;

Чәчәкле авылы;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Татарстан Республикасы Мөслим районының Татарстан урамындагы 1-35 номерлы шәхси йорт хуҗалыклары; Рәшитов урамындагы 22-52 номерлы шәхси йорт хуҗалыклары; Набережная урамындагы 1-40 номерлы шәхси йорт хуҗалыклары; Кооператив урамындагы 124-142 номерлы шәхси йорт хуҗалыклары;

Казан шәһәрендәге Конечная урамы;

Әлки районының Базарлы Матак авылындагы Хәмидуллин урамы;

Сарман районының Сарман авылындагы Высотная урамы;

Әлмәт шәһәрендәге Тюленин урамы;

Аксубай районының Яңа Илдерәк авылындагы Көньяк урамы;

Балтач районының Югары Шубан авылындагы Үзәк урамы;

Биектау районының Биектау авылындагы Совхоз урамы;

Татарстан Республикасының «Лениногорск урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесе Иске Куак участок урманчылыгының 10 нчы һәм 37 нче кварталлары;

Татарстан Республикасының «Алабуга урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесе Лубян участок урманчылыгының 97 нче кварталы;

Әлмәт районының «Туган табигать» коммерциячел булмаган оешма Фонды Бутино-Шешминск аучылык хуҗалыгының 109 нчы кварталы;

Әлмәт районындагы гомуми кулланыштагы аучылык җирләренең 52 нче кварталы;

Татарстан Республикасының «Кызыл Йолдыз урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесе Котлы Бүкәш участок урманчылыгының 48 нче кварталы;

Татарстан Республикасының «Минзәлә урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесе Актаныш участок урманчылыгының 14 нче һәм 211 нче кварталлары;

Татарстан Республикасының «Кама урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесе Шеморбаш участок урманчылыгының 14 нче кварталы;

Арча районының Арча – Яңа Кенәр юлы буендагы Үрнәк аучылык хуҗалыгы;

Арча районының Зур Бирәзә авылы янындагы «Шора» аучылык хуҗалыгы;

Лаеш районының Идел-Кама аучылык хуҗалыгының 1 номерлы обходы;

Мамадыш районының «Урман һәм К» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте Кама аучылык хуҗалыгы;

Минзәлә районының «Химпром» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте Яңа Минзәлә аучылык хуҗалыгы;

Спас районының «КИМ» совхозы поселогы янындагы мөгезле эре терлек асрау өчен 1 номерлы файдаланылмаучы җәйге лагере;

Буа районының Адав-Толымбай авылы янындагы авыл хуҗалыгы җирләре;

Кама Тамагы районының Олы Салтык авылы янындагы урман полосасы.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә карантин гамәле дәвам иткән вакытта түбәндәгеләр тыела:

йорт хайваннарын сату, аларны әлеге территориядән читкә чыгару, карантинлы территориядә һәм куркыныч янаган зонада кыргый җәнлекләрне (аларны зоопаркларга чыгару өчен, башка районнарда үрчетү максатларында һ.б.ш.) тоту;

котыру авырулы яисә авыру дигән шик тудыра торган хайваннарны ит өчен сую;

котыру авырулы терлекләрнең сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә пастеризацияләнмәгән сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә дезинфекцияләнмәгән йонын, тиресен әлеге территориядән чыгару.

3. Карантин, зарури чаралар күрү шарты үтәлгәндә, терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагы көненнән ике ай вакыт узгач бетерелергә тиеш, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә терлекләрнең котыру белән чирләвен бетерү буенча чаралар планнарын эшләргә һәм расларга, шулай ук аларның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 27 октябрь
№ ПУ-903

**1637. Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлеге сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерү турында**

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм**:

1. Терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Аксубай районының Такталы авылы;

Балык Бистәсе районының Олы Кульга авылы;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Биектау районының Бөреле җәнлек совхозы поселогындагы Уңышлы урамы;

Сарман районының Әлмәт авылындагы Ленин урамы;

Кама Тамагы районының Тәмте авылындагы Татарстан урамы.

2. Түбәндәгеләрнең үз көчләрен югалтуын танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Мөслим районы Тойгелде авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2012 елның 20 августындагы ПУ-683 номерлы Указының 1 пунктындагы «б» пунктчасы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2012 елның 20 августындагы ПУ-685 номерлы Указының 1 пунктындагы «а» пунктчасының икенче һәм дүртенче абзацлары, «б» пунктчасы.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 30 октябрь
№ ПУ-904

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1638. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, финанс-икътисад эшчәнлегендәге казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| «Девон-Кредит» акционер банкы (ачык акционер җәмгыяте) президенты киңәшчесе, Әлмәт шәһәре | Гомәров Нәфис Навык улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 30 октябрь
№ ПУ-905

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1639. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексын үстерүгә зур шәхси өлеше өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының финанслау бүлеге башлыгы | Гельман Александр Хаимовичны |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 30 октябрь
№ ПУ-906

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1640. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле эшчәнлеге өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы хезмәт ветераны | Данилов Вячеслав Власовичны |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 30 октябрь
№ ПУ-907

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1641. «Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте һәм Татарстан Республикасының төзелеш тармагын үстерүгә зур өлеше өчен

| | |
|---|---|
| «5 нче механикалаштырылган күчмә колонна» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте штукатур-маляры, Буа шәһәре | Насретдинова Рәшидә Мөнир кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 30 октябрь
№ ПУ-908

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1642. «Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирү турында

Татарстан Республикасының төзелеш комплексын үстерүдәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Казанның «Гидроспецстрой» махсуслаштырылган идарәсе ябык акционер җәмгыяте техник директоры | Гостев Юрий Николаевичка |

«Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 30 октябрь
№ ПУ-909

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1643. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Банк эшен үстерүдә һәм камилләштерүдәге казанышлары, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Девон-Кредит» акционер банкы (ачык акционер җәмгыяте) вице-президенты | Кузнецова Людмила Николаевнага |

«Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 30 октябрь
№ ПУ-910

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1644. «Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирү турында

Татарстан Республикасының юл-транспорт комплексын үстерүдәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең күпер корылмалары буенча эш сыйфатын контрольдә тоту һәм эшләрне кабул итеп алу бүлеге башлыгы | Сәфәров Ринат Флюр улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 30 октябрь
№ ПУ-911

### 1645. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Актив һәм нәтиҗәле эшчәнлеге, Татарстан Республикасында ветераннар хәрәкәтен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «Татарстан Республикасы сугыш һәм хезмәт ветераннарының Азнакай район оешмасы» җәмәгать оешмасын Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләргә
(тексты кушымтада бирелә).

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 01 октябрь
№ 446

## 1646. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре һәм халык сәламәтлеген саклау эшенә лаеклы өлеш кертүләре өчен:

| | |
|---|---|
| Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенең Бөгелмә районы һәм Бөгелмә шәһәрендәге территориаль бүлеге баш белгеч-эксперты | Мирсәяпова Светлана Салих кызына |
| Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенең Алабуга районы һәм Алабуга шәһәрендәге территориаль бүлеге башлыгы урынбасары | Шәрәфетдинов Айдар Юныс улына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 04 октябрь
№ 447

## 1647. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм халык сәламәтлеген саклау эшенә лаеклы өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе директоры | Гафуров Иван Мөбарәк улына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 05 октябрь
№ 448

## 1648. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Нәтиҗәле хезмәтләре һәм Татарстан Республикасының икътисадый үсешенә лаеклы өлеш кертүләре өчен Татарстан Респуб-ликасы Икътисад министрлыгы хезмәткәрләре:

| | |
|---|---|
| оештыру идарәсе башлыгы | Галиев Равил Борһан улына |
| режим, мобилизация әзерлеге, граж-дан оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр секторы мөдире | Латыйпов Шамил Нәгыйм улына |
| Инвестиция һәм инновация эшчәнлеге идарәсенең инновация эшчәнлеге бүлеге әйдәүче киңәшчесе | Локманова Альбина Наил кызына |
| Фаразлау һәм стратегик үсеш идарәсенең гомуми икътисадый фаразлау бүлеге башлыгы | Чугунова Надежда Павловнага |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 05 октябрь
№ 449

## 1649. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык намуслы хезмәтләре һәм Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексын үстерүгә лаеклы өлеш кертүләре өчен:

| | |
|---|---|
| Түбән Кама шәһәре «Түбән Кама нефтехимагропром» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте «Дружба» филиалының машина белән сыер саву операторы | Зарипова Татьяна Владимировнага |
| Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының «Нирус» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш ветеринария табибы | Нурмөхәммәтов Фәрит Вакыйф улына |
| Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Кырлай» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тракторчысы | Рәхимов Данил Камил улына |
| Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Ватан» авыл хуҗалыгы предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең терлек көтүен үрчетү технологы | Сәгъдиев Милис Искәндәр улына |
| Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы «Саба» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 6 нчы «Мичән» филиалы сыер савучысы | Яхина Гөлчәчәк Рәсим кызына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 05 октябрь
№ 450

## 1650. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык намуслы хезмәтләре һәм азык-төлек продукциясе җитештерүгә лаеклы өлеш кертүләре өчен «Татспиртпром» ачык акционер җәмгыяте хезмәткәрләре:

| | |
|---|---|
| баш инженерның граждан оборонасы һәм сәнәгать куркынычсызлыгы буенча урынбасары – техник идарә башлыгы | Лючева Любовь Владимировнага |

| | |
|---|---|
| «Татспиртпром» ачык акционер җәмгыяте филиалы – «Казан ликер-аракы заводы» продукцияне тутыру цехының азык-төлек продукциясе җитештерү линиясе операторы | Шәяхмәтова Гөлсинә Гаптулла кызына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 10 октябрь
№ 454

## 1651. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, мәдәни мирасны саклап калуга һәм үстерүгә зур өлеш кертүе, актив иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге өчен

| | |
|---|---|
| «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениесе директоры | Вәлиева Зилә Рәхимҗан кызына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 11 октябрь
№ 455

## 1652. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм Татарстан Республикасының җылылык-энергетика комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Урта Идел нефть продуктларын торбаүткәргечләр буйлап кудыру ачык акционер җәмгыяте генераль директоры | Купкенов Рафис Әнвәрбәк улына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 15 октябрь
№ 463

## 1653. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Нәтиҗәле хезмәте һәм Татарстан Республикасының юл төзелеше тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «Районара юл төзелеше идарәсе-1» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте коллективын Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләргә

(тексты кушымтада бирелә).

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 18 октябрь
№ 464

## 1654. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык педагогик һәм тәрбия бирү эшчәнлеге, яшь буынны үстерүгә һәм формалаштыруга лаеклы өлеш кертүе өчен Казан шәһәре Идел буе районының «19 номерлы гимназия» гомуми белем бирү муниципаль автоном учреждениесе коллективын Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләргә

(тексты кушымтада бирелә).

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 18 октябрь
№ 465

## 1655. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Ростинвенстгео» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры | Динмөхәммәтов Шамил Шәфикъ улына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 18 октябрь
№ 466

## 1656. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Нәтиҗәле хезмәте һәм Татарстан Республикасы икътисадын үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен «Девон-Кредит» акционер банкы (ачык акционер җәмгыяте) коллективын Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләргә

(тексты кушымтада бирелә).

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 20 октябрь
№ 467

## 1657. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Нәтиҗәле хезмәте һәм Татарстан Республикасы халкына пассажир транспорты хезмәте күрсәтүне тәэмин итүгә лаеклы өлеш кертүе өчен Казан шәһәренең «4 нче пассажир автотранспорт предприятиесе» муниципаль унитар предприятиесе коллективын Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләргә

(тексты кушымтада бирелә).

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 20 октябрь
№ 468

## 1658. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Татарстан Республикасы хакына нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Документлар белән тәэмин итү идарәсе редакторлар экспертизасы һәм тәрҗемәләр бүлеге башлыгы | Хәйруллина Лилия Әлһап кызына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 20 октябрь
№ 469

## 1659. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Нәтиҗәле хезмәтләре һәм Татарстан Республикасының метрология хезмәтен үстерүгә зур өлеш кертүләре өчен «Татарстан Республикасында стандартлаштыру, метрология һәм сынаулар уздыру дәүләт төбәк үзәге» федераль бюджет учреждениесе хезмәткәрләре:

| | |
|---|---|
| кадрлар бүлеге башлыгы | Коренкова Нина Николаевнага |
| мәгълүмат бүлеге башлыгы | Солодков Юрий Павловичка |
| сынаулар уздыру, сертификацияләү һәм үлчәү җайланмаларын тикшерү бүлегенең метрология буенча әйдәүче инженеры | Хисматуллина Дания Гиният кызына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 20 октябрь
№ 470

## 1660. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык иҗади эшчәнлеге һәм театр сәнгатен үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты | Сафин Нуриәхмәт Вәлиәхмәт улына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 20 октябрь
№ 478

## 1661. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Нәтиҗәле хезмәтләре һәм Татарстан Республикасының транспорт инфраструктурасын үстерүгә лаеклы өлеш кертүләре өчен:

| | |
|---|---|
| «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең автомобиль юлларын төзү һәм реконструкцияләү бүлеге баш белгече | Козлов Михаил Евгеньевичны |
| «Транспорт корылмаларын проектлау институты» ябык акционер җәмгыяте генераль директорының проектлау буенча урынбасары | Культяпов Александр Алексеевичка |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 20 октябрь
№ 479

## 1662. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Нәтиҗәле хезмәтләре һәм Татарстан Республикасы халкына пассажир транспорты хезмәте күрсәтүне тәэмин итүгә лаеклы өлеш кертүләре өчен Казан шәһәренең «4 нче пассажир автотранспорт предприятиесе» муниципаль унитар предприятиесе хезмәткәрләре:

| | |
|---|---|
| бухгалтер | Ковтун Лидия Васильевнага |
| директорның сервис хезмәте күрсәтү һәм гарантия буенча урынбасары | Сөләйманов Руслан Фәиз улына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 20 октябрь
№ 480

## 1663. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм Татарстан Республикасының мәгариф системасын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты җитәкчесе | Ногманова Людмила Николаевнага |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 30 октябрь
№ 484

## 1664. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык намуслы хезмәте, эшкуарлыкны үстерүгә зур өлеше һәм актив хәйриячелек эшчәнлеге өчен

| | |
|---|---|
| «РаМус» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры, Түбән Кама муниципаль районы | Мостафин Рафис Миңневәли улына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 30 октябрь
№ 487

## 1665. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Күпьеллык намуслы хезмәте һәм Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексын үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Суыксу» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры, Биектау муниципаль районы | Алимов Фиргать Мидхәт улына |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 30 октябрь
№ 488

## 1666. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Эчке эшләр органнарында намуслы хезмәте, оператив-хезмәт эшчәнлегендә югары нәтиҗәләргә ирешүе һәм хокук тәртибен ныгытуга, җинаятьчелеккә каршы көрәшүгә шәхси өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Менделеевск районы буенча бүлеге башлыгы | Сушков Геннадий Павловичка |

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен белдерергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

2012 ел, 30 октябрь
№ 489